ЮЛСЫЗЛЫК ГАЗАБЫ

«ВТ» хәбәрчесе Әгерҗе районындагы Яңа Бәзәкә авылы халкының гозерен тыңлады

> 6

ВАТАН ЧАКЫРГАЧ

Россия Герое Раил Габдрахмановның тормыш фәлсәфәсе турында

> 16

ГӨЛДАНИЯ ХӘЙРУЛЛИНА:

«Хәзер шөкер итеп яшим, мин бәхетле, дим»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 159 (28932) | Җомга | 28 октябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

МӘХӘББӘТ ТӘ – ХЕЗМӘТ

ГАИЛӘ КОРУ ӨЧЕН НӘРСӘ КОМАЧАУЛЫЙ?

Татарстан гаилә коручылар саны буенча Идел буе округында әле дә беренче. Демографик яктан тотрыклы саналса да, парсызларны ничек парлы итәргә һәм бәхетле гаиләләрнең ныклыгын ничек сакларга дигән сораулар республика өчен дә ят түгел. Ялгызлар-парсызлар да күп. Моны статистика да раслый. Әйтик, Россиядә беркайчан да өйләнмәгән һәм кияүгә чыкмаган 1,5 миллион кеше бар. Алар барысы да нәсел калдырырга сәләтле яшьтә санала. Халыкның гаилә кыйммәтләренә мөнәсәбәте ничек үзгәргән? Өйләнү ни өчен сөйләнү генә түгел? «ВТ» шуны ачыкларга тырышты.

> 5

Ишетми калмагыз

Россиядә ташламалы гаилә ипотекасы программасын озайтканнар. 2018 елның 1 гыйнварыннан 2023 елның 31 декабренә кадәр беренче (икенче һ.б.) баласы туган гаиләләр 6 процентлы ставка белән торак кредиты алырга мөмкин. Ипотека кредитын алар 2024 елның 1 июленә кадәр рәсмиләштерә ала. Мондый мөмкинлектән ул-лыкка (кызлыкка) бала алучылар һәм инвалид баласы булган гаиләләр дә файдалана ала. Ерак Көнчыгышта исә 2019 елның 1 гыйнварыннан соң туган бала тәрбияләүче гаиләләр дә 5 процентлы торак кредитына исәп тота ала.

Ипотека акчасының иң зур күләме Мәскәү, Петербург, Ленинград һәм Мәскәү өлкәләрендә – 12 миллион сум, калган төбәкләрдә – 6 миллион сум. Фатир сатып алу яки үз йортыңны төзү өчен беренчел кертем рәвешендә ана капиталын файдаланырга мөмкин.

Быел күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрына (ЕГРН) республикада яшәү өчен яраксыз дип, яки реконструкцияләнергә, сүтелергә тиеш дип табылган 2 меңгә якын объект турында мәгълүматлар кертелгән. Росреестрның Татарстан идарәсе мәгълүматларына караганда, барлыгы 358 күпфатирлы йортның авария хәлендә булуы билгеләнгән. Бу мәгълүматлар ЕГРНга дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары карары нигезендә кертелә. Идарә башлыгы урынбасары Лилия Борһанова аңлатып үткәнчә, хәзер күчемсез милекнең торышы ЕГРН документыннан өземтәдә күрсәтелә. Моңа кадәр мондый мәгълүматны җирле үзидарә органнарыннан гына алырга мөмкин иде.

Дәүләт Думасы традицион булмаган җенси мөнәсәбәтләрне (ЛГБТ) пропагандалауны тулысынча тыю турында закон проектларын беренче укылышта кабул иткән. Үсмерләр арасында мондый мөнәсәбәтләр тасвирламасын яки сурәтен тараткан өчен штраф күләме 5 миллион сумга кадәр җитәргә мөмкин.

Кинотеатрлар, башка платформалар җитәкчеләренә гадәти булмаган җенси мөнәсәбәтләрне сурәтләгән фильмнар күрсәтүгә лицензия бирү тыела. Мәгълүмат чараларында да мондый язмалар һәм реклама биреп булмаячак. Моннан тыш педофилияне пропагандалаган өчен штраф күләме 10 миллион сумга кадәр җитәргә мөмкин.

Ял көннәрендә Татарстанда һава торышы бозыла. Гидрометеоүзәк фаразына караганда, шимбә – 29 октябрьдә төньяк циклон яңгыр, юеш кар алып киләчәк. Һава температурасы асылда үзгәрми: көндез 0...+5 булса, төнлә –4...+1 градус. Якшәмбе – 30 октябрьдә бөтен республика күләмендә һава торышы начараю көтелә. Көндезге сәгатьләрдә термометрның терекөмеш баганасы +2...+7 градус, төнлә –2...+3 градус күрсәтәчәк. Киләсе атна башында юеш кар явасын, юлларда бозлавык буласын фаразлыйлар. Һава температурасы –1...+4 градус чикләрендә тирбәләчәк.

ЮХИДИ машина йөртүчеләрне игътибарлы булырга, юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәргә чакыра.

Районнарда ни хәлләр?

Түбән Кама

Районда халык шагыйре, язучы, җәмәгать эшлеклесе Разил Вәлиевнең 75 яшьлек юбилеена багышланган чаралар узды. Туган авылы Ташлыкта аның хөрмәтенә җирле мәдәният йортында әдәби-музыкаль кичә оештырдылар. Аннары ул шәһәрдә «Адымнар» полилингваль мәктәбендә укучылар һәм педагоглар белән аралашты. Бирегә яшь язучылар бәйгесе җиңүчеләрен бүләкләде. Тукай исемендәге Үзәк китапханәдә Разил Вәлиев елына йомгак ясалды. Юбилей уңаеннан шәһәр һәм район китапханәләрендә ел дәвамында фәнни-гамәли конференцияләр, онлайн акцияләр, әдәби кичәләр, конкурслар, язучының иҗаты буенча викториналар үткәрелде. Кичен Халык иҗаты йортында «Еллар аша сөйләшү» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә узды.
(e-nkama.ru)

Баулы

Васькино-Туйралы авылында яңа мәчет ачылды. Гыйбадәтханә төзелеше 2018 елның июль аеннан Рафаил Хәсәншин тырышлыгы һәм матди-финанс ярдәме белән алып барылды. Төзелешкә авылда яшәүчеләрнең, фермерларның, җирле җитәкчеләрнең дә өлеше керде. Мәхәллә тәкъдиме белән, яңа мәчеткә Рафаил хәзрәтнең әтисе – шулай ук игелекле эшләре белән мәгълүм Шәрипҗан абый хөрмәтенә «Шәрип» исеме бирелде. Имам-хатыйп вазыйфасына Рафаил хәзрәт Хәсәншин кереште. Татарлар, чуашлар, руслар яшәгән авылда моңа кадәр мәчет булмаган. Шулай итеп, Баулы мөхтәсибәтендә эшләүче мәчетләр саны 15кә җитте.
(Татарстан Диния нәзарәте)

Зәй

Поручик авылы мәктәбендә Дмитрий Милочкин истәлегенә хәтер стенды куелды. Дмитрий Луганск Халык Республикасы территориясендә махсус операция барышында һәлак булды. Аңа 22 яшь иде. Дмитрий Милочкин 2000 елның 1 февралендә Поручик авылының күпбалалы гаиләсендә туган. Чаллы төзелеш көллиятендә белем алган. 2019 елның 3 июлендә Сахалин өлкәсендәге хәрби частьта хезмәт итә башлый. Шул ук елны контракт төзи. Украинада махсус хәрби операция башлангач, ул Ватанны яклауга чакырыла һәм контракт буенча хезмәтен танк взводында дәвам итә.
(«Зәй офыклары»)

Азнакай

Районда исерек йөртүчеләрне махсус телеграм-канал аша ачыклыйлар. Моның өчен «ГИБДД Азнакаево» телеграм-каналыннан файдаланалар. Исерек килеш автомобиль белән идарә итүчеләр турында нинди дә булса мәгълүмат беләсез икән, аноним хәбәр бирү өчен @GIBDDAznakaevoBot адресы буенча язарга кирәк. Анда килгән барлык мәгълүматлар да район ЮХИДИ бүлеге инспекторларына юллана.
(«Маяк»)

НИГЕЗНЕ БЕЛҮ МӨҺИМ

tatarstan.ru

10,5 мең кеше. Иң өлкәненә – 72, иң яшенә – 16. Татарстан Конституциясе кабул ителүнең 30 еллыгы уңаеннан уздырылган бәйгедә катнашучылар турындагы мәгълүмат бу. Республиканың Төп Законын иң әйбәт белүчеләр белән Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин да очрашты.

– Моннан нәкъ 30 ел элек кабул ителгән Конституция Татарстанның күпмилләтле халкын бер йодрыкка туплады, республиканың нигезен тәшкил итә торган кыйммәтләрне тагын да ныгытты. Бу темага карата кызыксынуның югары дәрәҗәдә булуы безне бик сөендерә. Үз хокукларыңны һәм бурычларыңны белү, закон кушканча яшәү, чыннан да, бик мөһим, – диде парламент Рәисе, Татарстан Конституциясе кабул ителүнең 30 еллыгы уңаеннан уздырылган республика бәйгесендә җиңүчеләрне һәм призерлы урын алучыларны котлаганда.

Фәрит Мөхәммәтшин республика Конституциясенең катлаулы чорда – 1990 нчы елларда кабул ителүен искә төшерде, ул еллар турында җентекләп сөйләде.

«Татарстан Конституциясенең 30 еллыгы – үзеңне тикшер» конкурсында республиканың барлык районнары да катнашкан. Иң активлары – Нурлат, Түбән Кама, Арча районнары, шулай ук Казан һәм Чаллы шәһәрләре. «Татарстан Конституциясе: тарих һәм бүгенге чор» интеллектуаль уены исә юридик белем алучы студентлар арасында узган.

– Мондый бәйгеләрнең бурычы – әлеге мөһим документны кабул итү тарихын искә төшерү генә түгел, шушы еллар эчендә аның төп нигезләмәләренең тормышка ашырылуын анализлау да. Югары уку йортларының юридик факультетлары зур һәм җитди эш башкарган, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

ҖАВАП КӨТӘЛӘР

Бүген ярдәмнең берсе дә артык түгел. 27 октябрьдә Татарстанның профильле министрлыклары һәм ведомстволары, Дәүләт Советындагы хатын-кыз депутатларның «Мәрхәмәт» берләшмәсе вәкилләре өлешчә мобилизациягә кагылышлы сорауларга җавап бирде.

«Татар-информ»

Сораулар күп. «Бердәм Россия» партиясенең кабул итү бүлегендә оештырылган «кайнар линия»гә шалтыратучыларның күпчелеге – ирләре өлешчә мобилизациягә эләккән хатын-кызлар.

– Әлегәчә без хәл итә алмый торган сораулар килмәде. Кайбер сорауларны башкарма хакимият органнары белән хәл итәбез, ләкин күпчелек шалтыратучылар нинди булса да мәсьәләгә аңлатма кертүебезне сорый. Күп сораулар социаль түләүләр, мобилизациягә эләккән ирләрнең балаларын ашханәләрдә ризык белән тәэмин итү, кредит каникулларына бәйле. Соңгы сорау буенча банклар белән эшли башларга җыенабыз. Барлык таләпләрне дә тиешле дәрәҗәдә үтәмәүчеләр бар, – дип сөйләде «Мәрхәмәт» берләшмәсе җитәкчесе Алсу Нәбиева. – Шуны искәртергә кирәк: без шалтыратмаган һәр кешенең соравын ничек тә хәл итәргә тырышабыз. Аларга шәхси номерларыбызны бирәбез. Әгәр сорау хәл ителмәсә, кабат шалтырата алалар.

Ярдәм сорап кына түгел, тәкъдим итеп шалтыратучылар да бар. Андыйлар турында Татарстан Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе урынбасары Людмила Рыбакова сөйләде.

– Шалтыратучылар күп. Төрле эчтәлектәге сораулар белән мөрәҗәгать итәләр. Республиканың төрле почмакларыннан шалтыраталар. Һәр сорауга җентекләп җавап бирергә тырышабыз, үтенеч булса, аның үтәлүен контрольдә тотабыз. Шалтыратучыларның күпчелеге тегеяисә бу мәсьәләгә ачыклык кертүебезне сорый. Әйтик, Татарстанда өлешчә мобилизациягә эләккән ир-егетләрнең 18 яшькәчә булган балаларына бер тапкыр 20 мең сум акча түләнүе билгеле. Бер ханым, ирем белән аерылган очракта да, бу акча түләнәме, дип сорады. Әйе, чөнки әлеге ярдәм баланың законлы вәкиленә күрсәтелә. Шулай ук күңелне җылытырлык шалтыратулар да бар. Әйтик, берәүнең мобилизациягә эләккән егетләрнең җыелу пунктларына барып, анда концерт куясы килә. Егетләр өчен республика районнары концерт куя башлаячак, без шалтыратучыны тиешле кеше белән тоташтырдык, – диде ул.

Исегезгә төшерик, Татарстанда кабат «Ярдәм янәшә!» иҗтимагый хәрәкәте эшли башлады. Волонтерлар мобилизациягә эләккән егетләргә кирәк-яраклар җыю, аларның гаиләләренә ярдәм итү белән шөгыльләнә. Ярдәм сорап мөрәҗәгать итүчеләр күпме икән? Бу сорауга Татарстанның яшьләр эшләре министры урынбасары Алла Кондратьева җавап бирде.

– Әлегә мөрәҗәгатьләр саны бик күп түгел. Күбесенчә, көндәлек эшләрдә ярдәм итүне сорап шалтыраталар. Әйтик, авыл җирендә яшәүчеләр утын ярырга ярдәм итүебезне сорый. Безнең волонтерлар һәр районда бар, барып ярдәм итәләр. Гомумән, «Ярдәм янәшә!» хәрәкәте волонтерлары төрле юнәлештә эшли. Хәтта тәрбияче булып эшләүче волонтерларыбыз да бар. Алар бала караудa ярдәм итә ала, – диде ул.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Сүз уңаеннан

Татарстанда 16 яше тулмаган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияләүче 150дән артык мобилизацияләнгән ир-егетне чакырылыштан азат иттеләр. Билгеле булганча, бу эш узган атнада Татарстанның Чакырылыш комиссиясе чыгарган карар нигезендә башкарыла.

Моннан тыш, Россия Дәүләт Думасының Гаилә мәсьәләләре комитеты рәисе Нина Останина тагын ике категориядәге ир-егетләрнең мобилизациядән азат ителәсен әйтте. Болар – хатыннары өченче баласын көткән ир-егетләр, инвалид бала тәрбияләүче әтиләр.

СОРАУ БУЛСА ЯКИ ЯРДӘМ КИРӘК ЧАКТА

★122 номеры буенча «кайнар линия».
★«Объясняем.РФ» сайты.
★«Ярдәм янәшә!» хәрәкәтенең 8 (800) 350-02-16 номеры буенча эшли торган «кайнар линия»се

СӨЙЛӘШӘСЕ ДӘ, ЭНДӘШӘСЕ ДӘ ТҮГЕЛ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Күңелне алдалыйлар. Махсус операция башланганнан соң бераз тынып торган мошенниклар кабат эшкә керешкән. Хәзер алар корбанын махсус операциядә катнашкан, мобилизациягә эләккән кешеләргә ярдәм җыябыз ише сүзләр белән дә төп башына утырта икән. Бу җинаять, нигездә, телефон аша кылына.

– Августта мондый төр җинаятьләр саны кабат арта башлады. Моның белән билгеле бер дәүләт территориясендә яшәүчеләр шөгыльләнә дип өздереп әйтә алмыйм, әмма шулай дип уйларга җирлек бар, – дип сөйләде Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы Баш тикшерү идарәсенең бүлек җитәкчесе Марина Шнитенкова журналистлар белән очрашуда.

Мошенниклар махсус операциягә киткән, мобилизациягә эләккән кешеләргә генә түгел, качакларга да ярдәм итәбез дип алдап акча җыя. Хәтерләсәгез, әле күптән түгел генә шундый ысул белән Лениногорск районы башлыгын да төп башына утырта язды алар. Ставрополь краенда яшәүче ир-ат, мобилизациягә эләккән егетләргә ярдәм җыям дигән булып, аннан 60 мең сум акча сораган. Мордовия Республикасы башлыгы да мошенниклар корбанына әверелгән. Кырыгалдарлар аннан 230 мең сум акча таләп иткән. Якын арада бу эшләр судта каралачак.

Кырыгалдарлар электән ятлап кулланган алдау ысулларын да онытып бетерми анысы. «Туганыгыз юл һәлакәтенә очрады», «сезнең счеттан билгесез затлар акча урламакчы була» ише ялган сәбәпләр белән халыктан акча каеруын дәвам итә алар.

> Рәсми саннардан аңлашылганча, ел башыннан бирле Татарстанда телефон аша кылынган 10 меңләп мошенниклык очрагы теркәлгән. Алар аркасында республика халкы 200 миллион сумнан артык акчасын югалткан. Бу – татарстанлылар кырыгалдарларга көн саен 733 мең сум акча күчергән дигән сүз.

Татарстан дистанцион рәвештә кылынган җинаятьләр саны буенча, Мәскәү, Санкт-Петербург шәһәрләре белән Краснодар краеннан соң, Россиядә дүртенче урынга чыккан. «Татарстан – халкының керемнәре югары булган икътисади яктан алга киткән төбәк. Мошенникларны шул ягыбыз белән җәлеп итәбез дә инде», – ди Марина Шнитенкова.

Телефон аша кылынган мошенниклык очракларының 90 процентында кырыгалдарлар сүзен «туганыгыз юл һәлакәтенә очрады» диюдән башлый. Мондый сүзгә бирәү дә битараф калмаячак, билгеле. Марина Шнитенкова сүзләренә караганда, быелның өченче кварталында гына да шундый ысул белән җинаять кылган 98 кеше тоткарланган. Аларның сүзенә ышанып, татарстанлылар өч ай эчендә 17 миллион сум акчасыннан колак каккан.

Күбрәк өлкәннәр алдана. Әле күптән түгел генә Казанда яшәүче бер әби «бәлагә тарыган» баласына ярдәм өчен мошенникларга 1,5 миллион сум акча биргән. Ул гына да түгел: шәһәр үзәгендәге 13 миллион сумлык фатирын ярты бәясенә генә сатып, торыр җирсез дә калган ул. «Шуңа күрә ниндидер шикле счетларга акча күчерер алдыннан иң элек полициягә шалтыратыгыз», – дип киңәш итә белгечләр.

Мошенникларның дүрттән бере: «Билгесез затлар сезнең счеттан акча урларга маташа», – дип алдалый. Быелның өченче кварталында республика халкы аларга барлыгы 50 миллион сум акча күчергән. «Мондый төр сүзләргә еш кына 30–49 яшь арасындагы кешеләр алдана. Даими эше, табышы булган кешеләр бу», – ди Марина Шнитенкова.

Белгечләр бу урында даими рәвештә кабатлап килгән гади генә кагыйдәләрне искә төшерергә мәҗбүр. Банк хезмәткәрләре беркайчан да билгесез номерлардан шалтыратмый, шәхси мәгълүматны, телефонга килгән кодны әйтүне сорамый. Шикле зат белән сөйләшүеңне чамалап алуга ук телефонны куеп, полициягә шалтыратырга киңәш итә алар.

Сүз уңаеннан, соңгы арада мошенниклар телеграм-каналда да активлык күрсәтә башлаган. Шикле счеттан акча салдырып бирү кебек кебек кырын гамәлләрне башкару өчен кешеләрне нәкъ менә шуннан эзли алар. Шуңа күрә белгечләр «Телеграм»дагы эш тәкъдим иткән игъланнарга сагаеп карарга куша.

– Мондый ысул белән акча эшләп калырга теләүчеләрне кисәтәсем килә. «Телеграм»дагы билгесез затлар, фәлән әбинең өенә барып акча алып кайткан, шикле счеттан акча салдырып биргән өчен бер нәрсә дә булмаячак, дип ышандырса да, чынлыкта бу адымыгыз өчен сезгә дә җавап бирергә туры киләчәк. Россия Җинаять Кодексының 159 маддәсе нигезендә моның өчен ун елга кадәр иректән мәхрүм ителү яный. Мошенниклар ничек кенә оста булса да, без мондый җинаятьләрне ача беләбез. Хәтта күрше төбәкләрдән эш итүчеләрнең дә эзенә төшәбез! – дип кисәтте Марина Шнитенкова.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Ил өстендә...

Бер мәлне урамда егылдым. Болай дисәң, дөрес аңламыйлар да әле ул. Боксчыларны рингта күргәнегез булса, күз алдына китерә аласыздыр инде. Вәт менә боксчы күтәренке кәеф белән сикергәләп тора. Көндәшенә берне җиңелчә генә кундырып ала да шул шатлыктан тагын сикергәли башлый һәм шунда кинәт... Көндәшенең йодрыгына тап була һәм... Чайкалып китә... Билгесезлеккә оча башлый... Инде егылдым гына дигәндә тезләренә кунакларлык көч таба... Шул көенчә һушын җыя алмыйча беркадәр аңгыраеп тора. Күз алдына китерә аласыз инде?

Мин дә шулай күтәренке кәеф белән, сикергәләп дигәндәй, урам буйлап китеп бара идем, авыру дигән нәрсәнең күзгә күренмәс кулы китереп тондырды. Мин чайкалып киттем. Ныграк чайкалганмын бугай, бер мизгелгә фани дөньядан бөтенләй чыгып киткәнмен. Тик бер генә мизгелгә. Икенчесендә үземне кулга алып, асфальтка тотынып калдым. Торып бастым. Берәрсе карап торса дип, «на всякий случай» елмайган булдым – кайгыра икән дип уйламасын. Елмаю бик фәкыйрь килеп чыкты. Сәбәбен соңыннан гына аңладым – эчтәге әрнү давылы ирек бирмәгән икән. Атлаган саен нәрсәдер өзелгән сыман, нәрсәдер җиргә тарта, ниндидер утлы нәрсә... Кыскасы, эш хөрт инде...

Көч-хәл белән тукталышка килеп җиттем. Будкага сөяләп, телефонны тартып чыгардым. Ашыгыч ярдәм чакырырга исәп, болай итеп эләктереп алгач, тиз генә туктамый инде. Ләкин Ходайның ачы каһәре төшкән вакытка юлыктым – телефонның зарядкасы беткән иде.

Иплән кенә татарча сөйләшеп торган ике кыз янына килдем. Тик авыз ачарга насыйп булмады, болар мине күрү белән чыркылдап икенче якка качтылар. Йөргәнмен икән гомеремне заяга уздырып, кызлар куркытучы булып эшләсәм, әллә кайчан миллионер булыр идем. Шуннан бер абзый янына... Моның колагы ишетми булып чыкты, ә көчләрәк итеп кычкырырга минем хәл юк иде. Тагын бер-ике кеше янына бармакчы булган идем, болар минем шунда юнәлгәнне күрү белән я йомылдылар, я читкәрәк атлап киттеләр. Ахыр чиктә, бер хатын кача алмый калды һәм «скорый» чакырды. Ләкин «скорый» килмәде, я берәр җирдә «бөке»гә эләккәндер, я тәгәрмәче тишелгәндер – дөнья мәшәкате аларны гына урап узмый ич инде.

Ахыр чиктә мин автобуска кереп бастым. Кеше күп иде. «Без, татарлар, фәлән миллион!» яки «Безнең шәһәрдә фәлән хәтле кеше яши!» дип мактану гына рәхәт. Автобуста халыкның күплеге артык зур ләззәт бирми. Һәм их кызыгы – кеше күп җирдә гел хәлсез адәмне кысалар. Чирле кеше хәлсез була. Автобустан төшкәндә бер җир дә авыртмый иде инде, мин авырта идем – авыртуның үзе сыман идем.

«Менә моннан турыга гына чыксаң... Якынрак... Машина да күренми...» – дип берничә адым атлауга, тәртип сакчылары килеп чыкты. Болар үзләренә кирәгеннән башканы ишетмәделәр дә бугай. Ашык-пошык кына протокол тутырдылар да бүтән җинаятьчене эзләп киттеләр.

Кайтырга озак кына иде. Юл уңаенда бер поликлиника очрап, шунда кердем. Ләкин анда беркемне дә кабул итмиләр икән. Башта теркәлергә, шуннан электрон буенча язылып куярга кирәк. Ләкин аның бер файдасы да булмады түгел, аптекага кереп дару алдым. Һәм регистрациядәге кыз бик газаплануымны күреп ашыгыч ярдәм чакырды.

Менә шуның килгәнен көтеп утырам әле. Авырту басыла башлады. Шуңа сөенеп, уйланып утырам. Әгәр шундук хастаханәгә докторлар кулына барып эләксәм, ул чирне әллә нинди яхшы дарулар белән сыйласаң – мәңге китә белмәс иде әле, әбисенә кунакка килгән сыман ятар иде шунда. Ә болай, якты чырай күрсәтүче булмагач, берничә сәгатьтән үк табанын күтәрде. «Ил өстендә чыпчык үлми» дигән әйтем дөрес инде, бер карасаң.

Вәт менә илем, халкым, кешеләрем өчен горурланып утырам. Бергә булсак, әле без әллә нинди авыруларның күрмәгәнен күрсәтеп куып җибәрә алырбыз...

Әйтеп кенә бактым

Алма

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Быел җимеш агачлары әллә нишләде. Грушалар елка уенчыгы сымак матур гына асылынып торалар иде, кинәт бозыла башладылар. Ике алмагачның берсендә бер генә дә алма булмады. Быел ял итә, дип үзебезне юаттык инде. Аның каравы икенче алмагач күршесе өчен дә эшләде: ботаклары алма авырлыгын күтәрә алмыйча сыгылып төшә башладылар. Унлап терәү куярга туры килде. Әмма, ни хикмәт, алмалар вакытыннан иртә коела башладылар. Шап-шоп иткән тавышка төнлә дә сискәнеп уянгаладым.

Ниһаять, алма коелудан туктый башлады. Агачтагылары кызарып, балланып торалар. «Алма, пеш, авызыма төш», – дип көйләп йөрдем дә, төшкәнен көтмичә, берсен өзеп алдым. Пычак белән урталай ярган идем, эче черек булып чыкты. Икенчесен өзеп алдым: шул ук хәл. Карап торышка менә дигән алмалар югыйсә, корт кергән тишекләр дә, каралган урыннары да юк. Бакча күршем Фоат: «Синең агачың авыру», – дип куйды. Кәеф китте. Алмагач тирәсендә әйләнеп-тулганып йөри идем, башыма бер зур гына алма килеп төшмәсенме! Башка әллә нинди уйлар килә башлады. Хәтта әле XVII гасырда ук яшәгән, башына алма төшеп, бөтендөнья тартылу көче турында закон ачкан Исаак Ньютон искә төште һәм аның кебек: «Эврика!» – дип кычкырып җибәрә яздым. Башыма берәр җүнле уй килгән булса, бәлки, кычкырган да булыр идем. Әмма дөньясы буталган чакта уйлары да әйләнә дә тулгана бит аның.

Кеше гасырлар буе төрле ачышлар ясап килә, алар халыкка хезмәт итә, җәмгыять алга атлый. Шул ук вакытта «кешелек үз-үзен бетерәчәк» дигән фикер дә яши. Ә атаклы кинорежиссер Андрей Тарковский, тагын да алга китеп: «Кешелек үз-үзен юк итәр өчен бөтен нәрсәне эшләде», – дигән иде.

Без дә – җәмгыять агачы җимешләре. Әллә бу агач та авыру микән? Шуңа күрә без дә бозылабыз микән? Сүзем үзебезнең ил, үзебезнең җәмгыять турында гына түгел, бүген бөтен дөньясы әллә нишли.

Кайчандыр «мирный атом» дип җырлап йөрдек. Бүген кешелеккә хезмәт итәргә тиешле атом энергиясе кешелекне юкка чыгарырдай иң куркыныч коралга әйләнде. Сугыш-бәрелешләрдә «төп солдат» – заман техникасы һәм технологиясе. Кеше йөзәр, меңәр чакрым ераклыктан торып бер-берсен юк итә. Кесә телефоны аша кемнең, кайда икәнен ачыклау берни тормый. Шул телефон ярдәмендә төрле шартлаулар да оештырыла.

Алмагач тирәсендә шулай хыялланып йөргәндә, башыма тагын бер алма төште. Иң өске ботагыннан иде, ахрысы, башны авырттырды. Әмма, ни хикмәт, күңелдән генә үземә ачышлар ясый башладым. Дөнья болай барса, кешеләр бер-берсенең уен белерлек берәр җайланма уйлап тапсалар, ни булыр икән? Ир – хатынының, хатыны иренең ни уйлаганын белеп торса, гаиләләр нишләр икән? Тагын да ныгырлармы, әллә, киресенчә, таркалырлармы? Дөнья халыклары бер-берсенең «кай җире» белән уйлаганын белеп торса, тормыш кай якка үзгәрер икән?

Шәп төште соңгы алма башыма, уйларымнан һич аерыла алмыйм. Әгәр кешеләр күңеленә иң яхшы уйлар гына кертә торган бер җайланма уйлап табылса, дөнья нишләр? Мөгаен, җир йөзендәге бар халык үзара дус һәм тату яшәр, сугышлар-ызгышлар килеп чыкмас иде. Күңелдә шундый уйлар тудырган өчен алмага рәхмәт инде. Баштагы «шишка» бетәр, ә күңелдә рәхәтлек калыр. Бөтен эшләр хыялдан башлана бит, хыяллар да изге булсын иде.

МӘГАРИФТӘН БАШКА АЛГАРЫШ БУЛЫРМЫ?

Россия фәне турында бу сөйләшүгә мине университетларның Times Higher Education версиясе буенча дөньякүләм рейтингы этәрде. Безгә күптән мәгълүм инде: Россия университетлары мондый рейтингларда бик түбән урыннарда торалар, күбесе, гомумән, исемлеккә дә эләкми. Мең вуздан торган соңгы исемлеккә, мәсәлән, бары тик 5 югары уку йорты эләккән. Шуларның иң уңышлысы – Мәскәү дәүләт университеты – 163 нче урында. МФТИ – 200 нче баскычтан түбәндәрәк, Санкт-Петербург политехника университеты 300 нче баскычтан түбәндә. Иң югары баскычларны АКШ университетлары яулаган. Барысы 160 вуз – рейтингта дәрәҗәле урыннарда. Англия 92 вуз белән эләккән. Кытай 65 университетын исемлеккә кертә алган. Болар мине бик гаҗәпләндерми. Артта калган дип саналган илләрнең рейтингта Россияне узып китүләре кызыклы. Дистә еллар буе санкцияләр астында яшәгән Иран «топ»ка эләккән уку йортлары саны буенча безне ике тапкыр узып киткән. Хәзер бит мәгълүмат кырында шундый тавыш бара: Россия Украинаны Иран дроннары белән кыйный, диләр. Президентның матбугат үзәге башлыгы Песков әфәнде: «Кремльдә бу хакта берни дә белмиләр», – дип әйтә әйтүен.

Без көлеп һәм югарыдан карарга гадәтләнгән Согуд Гарәбстаны да бер позициягә бездән алдарак. Согудлардә халык саны 36 миллион гына, бездә берничә тапкыр күбрәк булуын искә алсак, хәл тагын да үкенечле. Чүл илендә университетлар саны да бездәгедән күпкә кимрәк бит инде. Әмма мин интернетның эзләү системасыннан Согуд Гарәбстаны вузларының рейтингта катнашуы хакында мәгълүмат эзлим дә «33 из 36 университетов в стране Саудовская Аравия представлена хотя бы в одном рейтинге» дигән хәбәргә тап булам. Гомуми рейтингтан тыш, аерым тармаклар буенча да рейтинглар бар әле. Согуд вузлары математика, робот техникасы, табигать фәннәре, информатика, фармация һәм фармакология юнәлешләрендә уңышлы катнашалар.

Россия университетларының рейтингка бик сыек эләгүе һәм артык абруйлы булмаган баскычларда гына торуы бездә югары белем бирү системасының бик әллә нәрсә түгеллеген дәлилли. Без аның нәтиҗәләрен үзебезнең сәнәгатьтә дә күрәбез. Югары технологик продукцияләр җитештерү белән мактана алмыйбыз. «Коммерсант» Кытайдан алган чипларның 40 проценты брак булуын яза әнә. Элек 2 проценты гына эшкә яраксыз булган. Хәзерге ватык микросхемаларны күпләп сатып алуыбызның төп сәбәбе: рәсми дистрибьюторлар безнең белән эш итүдән курка, кем эләксә, шуннан алырга туры килә. «Параллель импорт» дип аталган матавык кыйммәткә төшә безгә. «Ник үзебезнең микросхемаларны җитештермибез?» дигән сорауның җавабы гади: мөмкинлекләребез юк. Әйе, безнең вузларда бу юнәлештә бик күп кадрлар әзерләнә, нанотехнологияләрне өстенлекле юнәлеш иткәнебезгә дә байтактан, әмма нанометрлары кечкенә булган чиплар җитештерергә көчебездән килми. Бездә андый мәйданнар да юк, кадрлар да.

Болар турында язганда, мин «Российская газета»ның чәршәмбе санын ачтым һәм бик оят булып китте. «Как Россия может осуществить прорыв в микроэлектронике» дигән язмада Россия микроэлектроникасының АКШ белән Япониядән генә калышып, дөньяда өченче урында торуы язылган. Әмма язманы яхшылап укый башлагач, йөздән кызыллык китеп, яңадан агарды. «В конце 80-х годов наша микроэлектроника была на третьем месте в мире после США и Японии. Отставали всего на пять лет, но самое главное, что мы уверенно их догоняли», – ди Микроэлектроникада проектлаштыру проблемалары институты җитәкчесе, академик Александр Стемпковский. Ерак үткәндәге казанышлар бүген җылытмый шул. Ул чакта әле СССРда үз электрон машина төзелеше, микросхемаларны автоматлаштырылган проектлаштыру системалары булган, чипларның 75–80 проценты Россия җиһазларында һәм материалларыннан җитештерелгән. 1989 елда АКШтан килгән белгечләр: «Сез бездән бернидә дә калышмыйсыз», – дип таң калганнар. Тарихның шуннан соңгысын беләсез инде: академик сүзләре белән әйтсәк, 1992 елдан соң: «Была совершена стратегическая ошибка». Хәзер инде микроэлектрониканы нульдән башлап торгызырга кирәк. Россиядә җитештерелгән дип саналучы электрон җиһазлар барысы да чит ил технологияләре, чит ил җиһазлары, чит ил комплектлаучылары белән эшләнә. Хәзер болар барысы да – санкцияләр астында. 180 нанометрлы чипларны, импорт җиһаз ватылса, берничек тә җыя алмыйбыз. Алга киткән илләрдә хәзер 7 нанометрлы, хәтта 2–3 нанометрлы чипларны җиңел җыялар. Стемпковский

Илдар Мөхәммәтҗанов

әфәнде бу дәрәҗәгә ирешү өчен: «…нужны принципиально новая электронная промышленность, новые заводы, новые САПР», – ди.

Россия хөкүмәте 2030 елга кадәр микроэлектрониканы үстерү концепциясе эшләгән һәм моның өчен 3 триллион сумнан артык акча бүлеп бирергә җыена икән. Күп кенә белгечләр концепциягә шикләнеп карый, тормышка ашса да, уңышка китермәс, диләр, чөнки без куып барганда, башкалар тагын да алгарак китәчәк. Эш акчада гына түгел, белгечләр җитешми. Россиядә бу өлкәдә әле дә бик көчле белгечләр бар икән, әмма алар бармак белән генә санарлык. Ә дөньяның лидерлыкны үз кулында тотучы фирмаларының һәркайсында бернничә мең хезмәткәр тир түгә. Белгечләрне мәгариф системасы әзерләргә тиеш, әлбәттә. Әмма Россия вузларның хәле рейтингтан күренә. Мәгарифне бик масштаблы финанслаудан башка мәсьәлә чишелерлек түгел. Россия бюджетының алдагы еллардагы параметрлары «силовик»ларны финанслауны арттыруны күз алдында тота, фән һәм мәгариф исә үги хәлдә кала бирә.

Артта калган илләр дәрәҗәсеннән технологик товарлар экспортлый торган ил югарылыгына күтәрелү мөмкин ул, билгеле. Уганданың Россиядәге илчесе Мозес Кизиге безгә электромобильләр экспортларга җыенуларын әйтә әнә. Африка иле шундый теләкләр белән янгач (әле андый техниканы җитештерәләрдерме-юкмы), Россия баткаклыктан күтәрелеп чыга алырга тиеш тиешлеккә. Әмма моның өчен фәнни-тикшеренү оешмалары челтәрен үстерергә, аларны финансларга кирәк булачак. Чит илләрдә андый оешмаларны дәүләт түгел, хосусый бизнес финанслый. Ләкин бездәге хосусый югары уку йортлары белгечлек урынына диплом гына бирәләр шул.

Төркиядә 2008 елда бары тик 20 фәнни-тикшеренү үзәге булган. 2009 елда аларның саны – 62гә, 2010да – 82гә, 2011 дә – 110га, 2016да – 334кә, 2018дә 900гә җиткән. Темплар шаккаткыч бит. Үзәкләр төзеп кую гына түгел, аларны белгечләр белән тәэмин итәргә дә кирәк ич әле. Төрекләрнең күп өлкәләрдә, шул исәптән микроэлектроника тармагында да лидерлыкка омтылулары гаҗәп түгел. Әле яңа гына алар Tayfun дип аталган ракета сынап карадылар. Ризә-Артвин аэропортыннан атылган ракета, 561 километр араны уңышлы үтеп, максатка төгәл барып тиде. Әле кайчан гына төрекләрнең үз ракета программалары бөтенләй юк иде. Көнбатыш илләре аларга да санкцияләр керттеләр, хәрби техника ясауны кыенлаштырырга тырыштылар. Шуңа карамастан, төрек технологияләре төрле өлкәләрдә кызу темплар белән үсә. Россиягә шундый кискен борылыш ясау өчен мөмкинлек бар, файдалану-файдаланмау – югары җитәкчелек эше. Тамырдан үзгәртелгән сәясәт, тамырдан үзгәртелгән финанслау таләп ителә. Әлегә безнең технологияләр өлкәсендә эшләүче сирәк белгечләр дә мобилизациядән котылып кала алалармы-юкмы икәнне төгәл белмиләр. Гыйльми дәрәҗәсе булган белгечләргә бронь бирү хәл ителмәгән.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

МӘХӘББӘТ ТӘ – ХЕЗМӘТ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Парлыларның зары юк

Росстат Татарстанда яшәүчеләрнең гаилә хәле турында мәгълүмат белән уртаклашты. Коры статистика нигезен тәшкил иткән саннар чынлыкта зур проблемаларны ачып сала. Сан артында тол калганнар, беркайчан да гаилә кормаучылар, гаиләсен саклап кала алмаучыларның тормышы һәм моңа китергән төрледән-төрле сәбәпләр ята бит.

Былтыр үткәрелгән Бөтенроссия халык санын алу барышында республикада яшәүче **16** яшьтән өлкәнрәк **3268835** кешенең **3053600**е гаилә хәле белән уртаклашкан. Шуларның **1771983** – гаилә корып көн күрсә, **594319** кеше беркайчан да өйләнмәгән йә кияүдә булмаган икән. Республикада яшәүче **262399** кеше аерылышкан, **68** меңнән артыгы исә рәсми рәвештә теркәлмичә бергә яшәгән кешеләре белән араларны өзгән. **356223** кеше тол калуын әйткән. **215235** кеше гаилә хәлен күрсәтеп торуны кирәк дип тапмаган. Гаилә корып яшәүчеләрнең **1650866**сы нихакларын рәсми рәвештә теркәп гомер итсә, калганнары ир һәм хатын рәвешендә теркәлмичә генә яши.

Гаилә коручыларның яшь ягыннан статистикасы шулай ук кызыклы. Мәсәлән, 16–17 яшеннән үк никахлашканнар саны 418 икән. Шуларның яртысыннан артыгы гына рәсми рәвештә теркәлгән. Яшьли гаилә тормышыннан арып, аерылышырга өлгергәннәр дә бар. Андыйлар – 56 кеше. Бер тол калган үсмер дә бар дип ышандыра халык санын алу мәгълүматлары.

Ир һәм хатын булып рәсми рәвештә яшәүчеләрнең иң зур өлеше 35–39 яшь аралыгындагыларга туры килә икән. Андыйларның саны – 212907.

Уртак оя корып яшәргә ашкынып тормаган яшь категориясе исә – 20–24 яшьлекләр. Республикада бер мәртәбә дә өйләнмәгән йә кияүдә булмаган 136389 кеше исәпләнә икән.

Бу аңлашыла да, хәтта моның шулай икәненә ияләшеп тә барабыз төсле. Бу буын – бөтенләй башка тәрбия, кыйммәтләр белән үскән буын бит. Үз потенциалыңны тормышка ашыру, карьера баскычы буенча үрмәләү, беренче урынга «мин»не кую – болар әлеге яшь категориясенә караган егет-кызларда аеруча сизелә.

Төшәсе иде җиргә...

Гаилә кору башлангыч этапта ук әлегә кадәр бернинди уртаклыгы булмаган ике төрле кешедән күп көч, яраклашу сорый. Әмма хәзергеләрнең яраклашып торасы да, үз фикерен түбән куясы да килми. Таләпләр дә йолдызларга ашкан. Бигрәк тә хатын-кызларның. Гомер-гомергә гаилә учагын саклаучы кешедән күп нәрсә тора инде. Таләпләргә туры килми икән, аерылышырга да күп сорамыйлар. Күркәм сабырлык дигән сыйфатка таянып кына яшәү юк.

Гаилә кору һәм саклау үзәге директоры, «Россия мөселман хатын-кызлары» оешмасы рәисе Наилә Җиһаншина аерылышуга китергән сәбәпләрнең берсе дип коуч, блогер һәм психологларның популярлыгын атый. Араларны өзү генә түгел, мөнәсәбәтләрне коруга да алар киртә булып тормагае әле.

– Психологка мөрәҗәгать иткән хатын-кызны кияүгә бирү мөмкин түгел инде ул. Бу белгечләр аларны мөстәкыйль булырга, акча эшләргә, үз рәхәтеңдә яшәргә көйли, балалар үстергәнче йорт хайваннары тотарга киңәш итә. Әмма без – кешеләр һәм без нәсел калдырырга көйләнергә тиеш, – дигән фикердә белгеч. – Кайберәүләрнең таләпләре шулкадәр югары, аларны башта җиргә төшерергә туры килә хәтта. Фикер сөрешләрен үзгәртер өчен, Татарстанда димчеләр эшен җәелдерергә кирәк. Сүз уңаеннан, бу эшкә абыстайлар теләп алынды. Безнең үзәк аларны өйрәтте. Республиканың һәр районында бар алар. Казанда да – җидәү.

Гаилә – уңышка киртә. Гаилә, шәхси үсеш психологы, сексолог Дмитрий Соболев әйтүенчә, яшьләрдә әнә шундый фикер өстенлек итә.

– Яшь буын алдында бөтен дөнья ачык. Ләкин ул ачык дөньяга ачкыч яратыр өчен, бер урында туктап тормаска кирәк. Төрле ихтыяҗларны канәгатьләндерә торган тотрыклы нигез булдыру, үсеш,ниндидер максатка ирешү, нәрсәдер төзү, кору, яңадан-яңа дәрәҗәгә күтәрелү, алга бару... Ә гаилә, балалар алып кайту тырында сүз чыкса, аны яшьләр зур уңыш тәгәрмәченә таяк тыгу кебек кабул итә, – дип саный белгеч. – Гаилә кору – популяр түгел, кәттә түгел, яшьләрчә түгел. Гомер – бер генә, аны үзең өчен, рәхәт итеп яшәргә кирәк дигән фикердә торалар.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Гаилә бәхетен ничек сакларга?

Зөбәрҗәт Вәлиевага – 23 яшь. Университетның 1 курсын тәмамлагач, егете белән гаилә кора алар. Шулай иртә кияүгә чыгуның үз сәбәпләре бар иде, дип сөйли ул. Бар кеше уйлаганча, йөккә узу түгел, әлбәттә.

– Мин – кагыйдәләр кешесе. Минем өчен барысы да үз вакытында һәм билгеләнгән таләпләр буенча булырга тиеш. Мөнәсәбәтләр, гаилә очрагында да шулай. Егет белән кыз арасындагы мөнәсәбәтләр туйдан соң гына башка дәрәҗәгә күчәргә тиеш дип саныйм. Мине шулай тәрбияләделәр, – ди ул. – Булачак ирем белән очраша башлаганда, миңа 18 яшь кенә иде әле. Бәлки, шуңадырмы, тизрәк өйләнешергә булдык *(көлә)*. Йөргәндә үк: «Туйга кадәр бернинди дә җенси мөнәсәбәтләр булмаячак», – дип кисәттем. «5–10 ел йөрсәк тә, берни булмаячакмы?» – дип сораган иртә әле ул. Мин исә: «5–10 ел синең белән очрашырга җыенмыйм да мин, миңа үсеш кирәк, синең белән йөреп, мөнәсәбәтләрнең кызыгы да калмаячак бит инде», – дидем. 8 ай егет белән кыз булып йөрдек без. Кышын ул миңа кияүгә чыгарга тәкъдим ясады. Әле анда да уйландым, сынадым. Аның ышанычлы, әйбәт, миңа туры килерлек егет булуына инангач, ризалык бирдем. Кыскасы, 19 яшьтә үк кияүгә чыгу дигән зур максатым булмаса да, язмышыма шулай язылган булып чыкты.

19 яшьтә 27 яшьлек ирнең хатыны булу куркытмый Зөбәрҗәтне. «Яшьлегем-юләрлегем белән теге яисә бу эшне белмәсәм, иремә: «Барысын да белә торган 30 яшьлеккә өйләнәсең бар соң», – дия идем. Гаилә булып яши башлаганда мин әле 1 курсны бетергән студент кына идем бит. Бергәләп өйрәндек. Иптәш кызларым ял иткәннәрен, кайдадыр күңел ачканнарын социаль челтәрләргә куя, үз көенә яши... Боларны күреп, мин дә кызыга идем, билгеле. Шунысы да бар: ирем каты кысада тотмады, теләгем булса, җибәрә иде. Аның белән дә барырга була бит югыйсә. Әмма минем үрнәк һәм тыңлаучан хатын буласым килгәндер», – ди Зөбәрҗәт.

Бергә яши башлауларына тиздән 5 ел тула. Иртә кияүгә чыгуыма бер тапкыр да үкенгәнем юк әле, ди. Киресенчә, гаилә тормышы аны үзгәрткән, шуңа рәхмәтле булып яши.

– Холкым нык үзгәрде. Йомшаграк, назлырак булырга өйрәндем. Хатын-кыз нәзакәтлелеге барлыкка килде. Ә мин үзем лидер холыклы, дорфалык та бар иде. Кияүгә чыгып, дөрес эшләдем дип уйлыйм, – ди Зөбәрҗәт.

Дүрт бала анасы Лилия Галиәхмәтованы да матур гына тормыш башлап җибәргән гаиләләрнең һич көтмәгәндә генә таркалулары аптырашта калдыра. «Дөресен әйткәндә, ни өчен гаилә корудан куркалардыр – анысын әйтә алмыйм. Без инде 9 ел гаилә арбасын тартабыз. Азмы-күпме тәҗрибәбез дә бар дип әйтергә буладыр. Гаиләнең ныклыгы бер-береңне аңлау-санлаудан тора дип саныйм. Ә бу сыйфатлар әти-әни биргән тәрбиядән, әби-бабай үрнәгеннән килә. Минемчә, безгә шул тәрбия булганга күрә күпкә җиңелрәк. Барыбыз да – индивид, шәхес. Һәркайсыбыз үз фикерен алга сөрә. Алар кычкырышуга сәбәпче була ала. Безне, төшкән җиреңдә таш бул, дип өйрәттеләр. Гаилә корсаң, бер булсын, берәгәйле булсын, дип тәрбияләделәр. Безнең гаиләдә матур сүзләрне еш әйтәләр. Әмма гаилә булгач, төрлесе була. Кеше башына сыймаганнары да була тормышта. Татар тәрбиясенә хастыр инде ул: өйдәге чүпне тышка чыгармыйбыз, кешегә сөйләп йөрмибез. Татар хатын-кызларына хас сабырлык та үз эшен эшлидер. Гаилә башлыгының да, гаилә учагын саклаучының да диндә булуы да мөһим роль уйныйдыр һәм шайтан вәсвәсәсенә бирелмәс өчен бер киртә булып торадыр», – дигән фикердә әңгәмәдәшебез.

Ир һәм хатын мөнәсәбәтләре турында күбрәк белəм дисәң, Сәйдә абыстай Аппаковны тыңларга кирәктер, мөгаен. Гаиләнең әһәмияте һәм кыйммәте турында аннан да үтемле сөйләүче кем бар икән тагын?! Аның сүзләренчә, элек аерылышулар ун елга бер булып, анысында да ире күңелсезлеккә юлыкса яки хатынын рәнҗетеп яшәсә генә, хәзер хәлләр башкачарак. «Хәзер тамагыбыз тук, өстебез бөтен, гыйлемебез бар, ә никахны саклый белмибез. Оят! Моның сәбәпләре дә ярылып ята: телебезне тыя белмибез. Ачу ике минут кабарып тора да, аннан сүрелә. Сүрелгәнче әйтәсен әйтеп тә бетерәбез. Авызга элмәк кирәк!» – ди абыстай.

Тәрбия юклыгын да гаилә коручыларның аз булуына сәбәп итеп карарга мөмкин. «Борынгылар дин ничек кушкан, шулай яшәгән, баласына да унбиш яшенә кадәр әдәп-әхлакны, динне, традицияләрне төшендергән. Аны карадан аерырга өйрәткән. Тәрбия дигән олы нигъмәтне бала күңеленә салуны балалар бакчасына да, мәктәпкә дә йөкләмәгән. Ә бүген киресен күрәбез», – ди ул.

Теманың дәвамы 11 нче биттә >

Зөһрә САДЫЙКОВА

ҖИТМӘГӘН ЧАКРЫМНАР

ЯҢА БӘЗӘКӘ АВЫЛЫ ХАЛКЫ ЮЛСЫЗЛЫКТАН ТИЛМЕРӘ

Әгерҗе

Автокибет килми, балалар мәктәпкә йөрми, ашыгыч ярдәм, чүп җыю машиналары керә алмый. Язгы-көзге пычрак көннәрдә Әгерҗе районының Яңа Бәзәкә авылында тормыш туктала. Халык чарасызлыктан нәрсә эшләргә дә белми... Редакциягә хатлар һәм фотолар күтәреп килеп кергән Фирдәвес Уразманов үз гозерен безгә әнә шулай дип җиткерде. Чакрымнар узып килүенең сәбәбе җитди – авылга юл кирәк.

Юлсызлык

Фотолардан һәм Фирдәвес Уразмановның сөйләвеннән аңлашылганча, Яңавыл һәм Яңа Бәзәкә авыллары арасындагы 5 чакрым озынлыктагы юл бик начар хәлдә. 1985 елда колхоз өйгән дамба юл икән бу. Колхоз яшәгән чорда аның өстен, гравий җәеп булса да, ремонтлап торган булганнар.

– 2004 елда колхоз беткәннән бирле юл ремонтланмый, юл өсте юыла-юыла, ташы агып бетеп, кызыл балчыкка калды. Шуңа күрә язын-көзен, яңгырлар яуганда, юлдан йөрү бик зур җәфага әйләнә, – диде ул.

Ә юл бик кирәк. Мәктәп булмаганлыктан, балалар күрше Тирсә авылы мәктәбенә автобуста йөри икән.

– 2011 елда мәктәпләрне эреләндерү башланды. Бу эш безнең Яңавыл мәктәбен дә читләтеп үтмәде. Балалар саны җитәрлек булуга да карамастан, мәктәпне яптылар һәм Тирсәгә автобуста укырга йөртә башладылар. Яңавыл – Яңа Бәзәкә юлы начар булу сәбәпле, ата-аналар ризасызлык белдергәч, район җитәкчелеге, 2010–2013 елларда бу ике авыл арасына асфальт юл салыначак, дип тынычландырды. Шушы буш вәгъдәләр белән 11 ел вакыт узып китте, юлыбыз елдан-ел начарланды. Язын, бик нык пычрак булгач, беркинди дә машина йөри торган булмады. Шуңа күрә балалар читтән торып укыды, – диде Фирдәвес Уразманов.

Шулай ук авылда кибет һәм фельдшер пункты булмаганлыктан, автокибет, Яңавыл авылыннан медицина хезмәткәрләре дә килеп йөри.

– Яңгырлар башлангач, автолавка авылга керә алмый, укучыларны «Нива» машинасында йөртәбез. Янгын чыга калса, кеше авырып китсә дә, кот алынып тора. Чөнки ашыгыч ярдәм машинасы авылга керә алмый. Авыруларны Яңавылга тракторда алып төшкән вакытлар да булды, – ди авыл халкы.

Бүген авылда 85 кеше яши. Моңа кадәр халык үз проблемаларын үзе хәл итәргә тырышкан. Үзара салым акчасына сууткәргечләрне, чишмәләрне, зиратларны карап-төзәтеп торалар. Тик әлеге акча төбәк юлы статусында булган ике авыл арасындагы юлны эшләр өчен каралмаган.

– Яз-көз айларында «Шевроле-Нива» белән дә үтеп булмый. Юл өзеклеге аркасында язын 3 атна азык-төлек алып килә алмадылар. Юлыбызны өметсез, кирәксез дип әйтүчеләр дә булгалады. Ләкин без бу фикер белән бер дә килешмибез. Яңа Бәзәкә белән Удмуртия Республикасындагы Алнаш районының Кужем авылы арасы 3 чакрым гына. Юл яхшы булганда, аннан машиналар да, «Ак Барс» агрофирмасының техникалары да күп йөри, – ди Фирдәвес абый.

Авыл халкы әйтүенчә, документларда бу юл «переходное покрытие», ягъни ком-таш кушылмасы, гравий белән түшәлгән дип күрсәтелгән, ләкин юлга бервакытта да буеннан-буена каты вак таш җәелгәне булмаган. Алар сүзләренчә, юлның проекты да әзер, экспертиза да ясалган, юл билгеләрен, автобус тукталышларын да эшләп куйганнар. Ләкин халыкның зарыгып көткән юлы әле дә булса юк.

– Балаларыгызны күрше авыл мәктәбенә йөртегез – юл була, фермерлар санын арттырыгыз – юл була, диделәр. Тик болар барысы да буш сүз булып чыкты. Асфальт юл салу турында берничә ел сөйләләр инде, ләкин кайдадыр тоткарлык килеп чыга, күрәсең, – ди юлсызлыктан тәмам гаҗиз булган авыл халкы.

«Айга менү кирәкми»

Авылны өметсез дип әйтеп булмый. Халык ничек тә тырышып көн итә. Күпләп мал асрыйлар, умартачылык, игенчелек белән шөгыльләнәләр, агрофирмада эшләүчеләр дә бар. Ике фермер күпләп терлекләр тота, мини-ферма төзүчеләр дә бар. Кызганыч, юлсызлык аларның эшчәнлегенә дә тискәре йогынты ясый.

Әйтик, фермер Дилүс Ямалеев хуҗалыгында 30лап үгез, берничә баш сыер бар. Билгеле инде, күпләп мал-туар асрагач, техникасы да, йөрүе дә күп.

– Капка төбенә чыккач, уңга барсам, батармынмы, сулга китсәм, чумармынмы, алга китсәм, туктап калырмынмы, дип баш ватабыз. Бу бит һәр көнне шулай. Барырга кирәк, дип чыгабыз: таудан менеп булмый. Районнан ярминкәгә чакыралар, чыгабыз, батып, кире борылабыз. Һәр кешенең яхшы шартларда яшәргә, яхшы юллардан йөрергә хокукы бар, дип сөйлиләр. Без кеше исәбенә кермибез микәнни соң? Күрше авылга асфальт 26 ел элек салынган иде. Без әле дә шул килеш яшәп ятабыз, – диде ул.

Фермер әйтүенчә, юлсызлыктан яшьләр дә, өлкәннәр дә иза чигә.

– Чүп машинасы ике ай килә алмый инде. Акчасы да түләнгән югыйсә. Нинди зур машина да керми. Ә безгә язын-көзен көн саен җиңел машина белән саз ерып йөрергә кирәк. Чыккан саен юарга кирәк. Балалар кайта башласалар да, керә алмыйча, җәфаланып бетәләр. Дөресен генә әйткәндә, без утраудагы кебек яшибез. Юл вакыт-вакыт бар, вакыт-вакыт юк. Авыл халкы язны-көзне бик сагаеп көтеп ала, – ди Дилүс абый.

Мондый авырлык фермерлык эшчәнлегендә дә чагыла, ди ул. Киләсе елга да юл булмаса, терлек санын киметмәкче була.

– Асфальт булмаган очракта да, комташ кушылмасы булса да түшәсеннәр иде. Күрше Удмуртия Республикасы авыллары урамнарының бар җиренә асфальт, щебенка җәйгәннәр. Ник бездә юк? Кайтасы кеше – кайта, чыгасы кеше чыга алмый. Иртәгә нинди һава торышы булыр икән, барасы җиребезгә бара алырбызмы, дип көтеп утырырга туры килә. Телевизордан әллә нинди казанышлар турында сөйлиләр. Айга кадәр менәләр бит хәзер. Безгә ае кирәкми, 5 чакрым гап-гади юл гына салсыннар, – дип ачынып сөйләде фермер.

Авыл халкы Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка да хат юллаган.

Өмет

Авылдашларының сүзләрен авыл җирлеге башлыгы Мәгъсүм Сәлихов та раслады.

– Бу көннәрдә, чыннан да, бик пычрак. Халык бик иза чигә бу юлда. Җиңел машиналар йөрерлек түгел, ә авылдан керү-чыгу өчен бердәнбер юл бу. Ә исән кешегә юл көн саен кирәк, – диде ул. – Көн туса, янгын чыкмасын иде дә апаабыйлар гына авырып китмәсен иде, дип телим. Чөнки яңгырлы көннәрдә йөрерлек түгел. Фермерларыбызга да авыр. Җитештергән продукцияләрен сатарга, терлек азыгы юнәтергә кирәк.

Аның сүзләренчә, бу проблеманы район җитәкчелеге белә, хатлар да юлланган.

– Барысы да көтә. Расланган очракта, иң беренче булып безнең авылга юл керәсе, дип вәгъдә бирәләр. Белмим, тагын шул вәгъдәләр белән генә калырбызмы...

Халыкны бик нык борчыган әлеге мәсьәлә буенча без Әгерҗе районы башлыгы Азат Вәлиевкә шалтыраттык.

– Киләсе елда Яңа Бәзәкә авылына юл булыр, дип көтәбез. Программа тулысы белән кертелгән, ләкин әлегә ахырга кадәр расланмаган. Әгәр бар да без планлаштырганча булса, 2023 ел ахырына кадәр эшләрне төгәлләү бурычы куябыз. Өмет бар үзе. Президентка да хатлар юлланды. Безгә хәзер көтәргә генә кала, – диде Азат Вәлиев.

3 ноябрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Динә Гыйлаҗиева** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Газеталарны ник таратмыйлар?

«ВТ» газетасы шимбә санында һәр атнада диярлек укучылар хатларыннан торган бит чыгара. Шуны яратып укыйбыз, үзем дә күптәннән язгалыйм. Әмма шимбә почтасын нигәдер сишәмбе көнне генә тараталар. Нишләп шимбә, якшәмбе, дүшәмбе почтальоннарга эшләргә ярамый икән? Минем Азнакай, Бөгелмә, Казан китапханәләрендә кызыксынганым бар: аларда да почтаны көнендә китерү гадәте юк. Халыкны көндәлек матбугаттан читләштерү өчен махсус эшләнгән корткычлык түгелме бу?

Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.
Азнакай

Азнакай почта бүлеге җитәкчесе Резеда Җәләева:
– Бездә почтаны дүшәмбе, чәршәмбе һәм шимбә көннәрендә тараталар. Җомга иртән килеп ирешкән газеталар шул ук көнне укучыларга барып җитә. Газета укучысы Хәким Гыйләҗев Урсай авылында яши. Андагы почта хезмәткәре авырып алган иде, бәлки, шул сәбәпле берничә тапкыр газеталар вакытында таратылмагандыр. Гомумән алганда, вакытында китереп җиткерергә тырышабыз. Җомга матбугаты – шул көнне яки шимбә, ә шимбә килгәне дүшәмбе көнне укучыларга барып ирешә.

Акчаны кайтарып буламы?

Йортка газ керткән өчен түләнгән акчаның бер өлешен салым яки субсидия рәвешендә кайтарып булмасмы икән?

Гөлия ИБРАҺИМОВА.
Казан

Россия Салым федераль хезмәтенең Татарстан буенча 5 нче районара салым инспекциясенең бүлек җитәкчесе Мөнир Шәйдуллин:
– Россия Салым кодексында йортка газ керткән өчен түләгән суммадан салым вычеты нигезендә акчаны кире кайтару каралмаган.

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәте:
– 2022 елдан аерым бер категория кешеләргә йорт участогы эчендә газ керткән һәм йортка газ җиһазы алган өчен бер тапкыр субсидия бирелә. Йорт милке дигәндә индивидуаль торак төзелеше объекты яки аерым төзелгән торак йорт һәм аның янәшәсендәге һәм (яки) уртак гомуми торак төзелеше яки торак йорт белән аерым торучы каралты-кура төзү (гараж, мунча (сауна, бассейн), теплица (кышкы бакча), терлек һәм кош-корт тоту өчен булмәләр, башка объектлар) аңлашыла.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: субсидия гражданнарның аерым категорияләрен газлаштыру (социаль газлаштыру) чаралары кысаларында өстәмә ярдәм булып тора. Социаль газлаштыру газ кертелгән торак пунктлардагы йортларның чикләренә кадәр бушлай газ кертү дигәнне аңлата. Бу очракта бер генә объектка бушлай газ кертү каралган. Әгәр моңа кадәр участоктагы иске объектка газ кертелгән икән, субсидия бирелми.

80 мең сумнан артмаган ярдәмне түбәндәге категория кешеләр яшәгән гаиләләр ала: Бөек Ватан сугышы ветераннары, I һәм II группа инвалидлар, инвалид бала. Шулай ук бу ярдәмгә кереме җан башына 10 мең сумнан азрак булган күпбалалы гаиләләр өметләнә ала. Аена 10000 – 19000 сум кереме булган гаиләләргә бер тапкыр бирелә торган субсидия йорт участогы чикләре эчендә газ үткәрү һәм йорт эчендә газ җиһазлары сатып алу өчен 60000 сумнан артмаган факттагы чыгымнар күләмендә бирелә.

Каналлар бушлай булырга тиешме?

Безнең йортта ике телевизор эшли. Беренчесе өйнең тышкы стенасындагы тәлинкә формасындагы антеннага тоташкан. Ул телевизорны минем гаиләм карый. Икенчесе түбәдәге антеннага тоташкан. Анысы 20 каналны күрсәтә. Бу каналларны көйләгәндә, бушлай булуын әйткәннәр иде. Ләкин «Таттелеком»нан август ае өчен 539 сум түләргә дип килде. Алар хаклымы? 20 канал өчен акча түләттерергә тиешләрме?

Федор АНТИПОВ.
Арча районы Шурабаш авылы

«Таттелеком» акционерлык җәмгыятенең матбугат үзәге:
– Сез шалтыраткач, без әлеге оператор белән элемтәгә кердек. Бераз аңлашылмаучылык булган икән. Федор Антипов өлкән яшьтә булу сәбәпле, килеп чыккан хәлне дөрес аңламаган. Ул балалары һәм оныклары белән яши. Алар интернеттан файдалана. Түләргә бер-ике көнгә соңга калгач, хезмәткәрләр телефонга шалтыратып, түләргә кирәклеге хакында кисәткәннәр. Бабай, начар ишетү сәбәпле, телевизорны сүндереп куялар дип аңлаган. Федор Антиповның бүлмәсенә, чыннан да, 20 канал карар өчен приставка куелган һәм ул бушлай.

РӘХМӘТ СҮЗЕБЕЗ

Кадерлебез Фатыйх Сәүбән улы Сибагатуллинның бакыйлыкка күчүенә дә дүрт айдан артык вакыт үтте. Бик сагынабыз, юксынабыз. Элеккеге хезмәттәшләре, фикердәшләре, якыннары, таныш-белешләре дә әледән-әле хәл белешеп, искә алып торалар. Үтә игелекле, халкыбызның үсеше, республикабызның чәчәк атуы өчен җан атып яшәүче күркәм зат иде ул.

Республикабыз җитәкчелеге дә гаиләбезне ярдәменнән, булышлыгыннан ташламый. Шушы уңайдан Президентыбыз Рөстәм Нургали улы Миңнехановка, Казан шәһәре хакимияте башлыгы Илсур Рәис улы Метшинга олы рәхмәтебезне җиткерәбез. Көннәребез тыныч, аяз булсын, татулык, дуслык, бердәмлек кыләчәктә дә күркәм уңышлары белән сөендереп торсын, дип телибез.

Фатыйх Сәүбән улының
тормыш иптәше Рәдифә, балалары, туганнары

Укучы фикере

«54 ЕЛДАН СОҢ КИЛГӘН БӘХЕТ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ
Бер яктан сөенеч, ә менә 60ны узгач, беренче сыйныфка алып бару, өйдә бала белән дәрес хәзерләүләр… Сезгә дә, балагызга да тазалык, озын гомер, сабырлык телим.

Раушания УСМАНОВА

* * *

Мин бишенче балам – кызымны 46 яшьтә алып кайттым. Бер кызым 20 яшендә гүр иясе булды. Ул безне ташлап киткәч, бик авыр кичердем. Алга таба яши алмам төсле иде. Тик, Аллаһка шөкер, әле ярый шушы баламны табып үстергәнмен, дим. Инде аңа да – 24 яшь. Сез дә хәзер туган сабыегызга шатланып, исән-сау үстерегез. Сез аның белән яңадан яшәреп китәрсез.

Фәридә САДАРДЫНОВА

«КӨЧЕМ – КУЛЫМДА» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ
Дәвалаучыларга хастаханәдән өметен өзгән кешеләр бара инде. Мөслимә апага барып терелгән кешеләрне беләм. Хастаханә ярдәм итмәгән, аяксыз калган кешеләр терелде. Умырткадагы бөсердән котылдылар. Тәмәкене ташлаучылар да бар. Аларга үз теләкләре кирәк инде.

Гөлсирин ГЫЙРФАНОВА (МОСТАФИНА)

* * *

Бөкрене кабер генә төзәтә, ди. Бар нәрсә кешенең үзеннән тора. Безнеке юлга 2000 түләп барды. Шунда ук эчә башлады. Кеше шуңа ышанып бара инде.

Рәйхана РӘХИМОВА

«СОЛДАТЛАРГА – ЙОКЫ КАПЧЫГЫ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ
Күпме ир-атларыбыз сугышка чыгып киткәндә, кибетчеләр, бәя арттырып, акча эшлиләр. Хәзер адәм баласының ояты качкан инде. Солдатларга диган әйберләрнең бәясен төшерергә кирәк югыйсә. Гаиләләрен, газиз кешеләрен калдырып, шушы илне сакларга бара бит алар. Кемдер тизрәк файдаланып калу юлын эзли. Рәхмәт сезгә, кызлар, сәламәт булыгыз.

Гүзәлия ШӘРӘФИЕВА

Рәхмәт ишетү рәхәт

Биектау районының Ямаширмә авылын Казан – Малмыж трассасы белән тоташтыручы юлга яңа асфальт җәюләрен сорап, «ВТ» газетасына мөрәҗәгать иткән идек. Чөнки бу юлдан һәркөн диярлек күп кеше үз машинасында якын-тирә районнарга, Казан шәһәренә эшкә йөри. Күрше авыллардан Ямаширмә урта мәктәбенә ике автобус балаларны укырга йөртә. Бу юлны рәтләү безнең өчен бик мөһим иде. Ниһаять, республикабыз җитәкчелеге, район хакимияте башлыгы һәм газета журналисты Сәрия Мифтахова тырышлыгы белән быел әлеге теләгебез тормышка ашты. Бик зур рәхмәт сезгә!

Ямаширмә авылы халкы

Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде

Салым турында 6 сорауга җавап

Онытмаган булсагыз, 1 декабрьгә кадәр физик затларга милек салымын түләргә кирәк. Шуңа бәйле кайбер сорауларга җавапны салым консультанты Зөлфия ЛОТФИЕВА җавап бирде.

:: Салым түләмәскә ярыймы?
– Юк. Әгәр дә салым түләүне вакытында башкармасагыз, салым хезмәте сезгә моны таләп итеп хәбәр җибәрәчәк. Инде таләп ителеп тә, салым түләнми икән, физик заттан аны суд приставлары аша түләттерергә мөмкиннәр. Штраф һәм пеня да өстәлә. Суд приставы бурычлы кешегә чит илгә чыгуны тыярга мөмкин.

:: Салым суммасын мөстәкыйль рәвештә исәпләп чыгарырга мөмкинме?
– Әйе. Әйтик, милек һәм җир салымының күләмен беләсегез килә, ди. Моның өчен объектның кадастр бәясен белергә кирәк. Транспорт салымы икән, машинаның ат көче һәм ставкасы исәпкә алына.

:: Салымны туганың өчен түләргә мөмкинме?
– Ир, хатын, туганың өчен салым түләргә ярый. Моны банк аша башкарырга була. Квитанция тутырганда кем өчен түлисез, шуның турында мәгълүмат язарга кирәк.

:: Салым түләргә тиешле кеше теркәлү урыны буенча яшәмәсә, ул салым түләүне искәртүче хатны кайдан алачак?
– Теркәлү урыны буенча яшәмәсә, хат аның «шәхси кабинеты»на киләчәк. Гадәттә ул сентябрь аенда ук килә.

:: Пенсионер, физик мөмкинлекләре чикле кешеләргә салым буенча ташламалар бармы?
– Пенсионерлар милек салымыннан азат ителә. Инвалидлар исә милек, җир һәм транспорт салымын түләми. Күпбалалы гаиләләр өчен дә ташламалар булырга мөмкин. Кайбер төбәкләр, шәһәрләр үзләре үк ташламалар кертә ала.

:: 18 яше тулмаганнар да салым түлиме?
– Әгәр дә алар да милек иясе икән, 18 яше тулмаганнар да салым түли.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

31 октябрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телесериал 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». Телесериал 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «БЕРДӘНБЕР» (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45 «Татар халык җырлары» 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00, 00.15 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Соотечественники» 12+
01.05 «Ватандашлар» 12+
01.30 «Каравай». Фольклорная кузница талантов 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Татар халык җырлары» 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Мирхәйдәр Фәйзи турында телеочерк 6+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.05, 22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Мирхәйдәр Фәйзи турында телеочерк 6+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. Максим Матвеев в многосерийном фильме «ТРИГГЕР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Андрей Смоляков, Александр Горбатов, Марина Александрова, Дарья Урсуляк, Сергей Газаров, Кирилл Зайцев, Александр Устюгов, Виктор Добронравов, Андрей Мерзликин, Филипп Ершов, Агриппина Стеклова, Светлана Колпакова. «ХУДОЖНИК» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
03.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Кёртис Блейдс против Деррика Льюиса. Трансляция из США 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 16.50, 19.10 Новости
07.05, 16.10, 23.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25, 18.05 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20, 04.00 «Катар. Обратный отсчёт» 12+
14.25 Дзюдо. Чемпионат России. Прямая трансляция из Екатеринбурга.
15.40 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 0+
16.55 Смешанные единоборства. UFC. Келвин Кэттер против Арнольда Аллена. Трансляция из США 16+
19.15 «Громко». Прямой эфир
20.25 Футбол. Чемпионат Италии. «Верона» – «Рома». Прямая трансляция
22.30 Тотальный футбол 12+
23.55 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Пари НН» (Нижний Новгород) – МБА (Москва) 0+
01.55 Футбол. Чемпионат Германии. «Унион» – «Боруссия» (Мёнхенгладбах) 0+
03.55 Новости 0+
05.00 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «БАЛАБОЛ» 16+
22.10, 00.00 Гоша Куценко. «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
02.45 Сериал «ЗВЕРОБОЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «6 кадров» 16+
06.50 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.20 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.30 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Крысобой» 16+
14.10 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «ОСКОЛКИ СЧАСТЬЯ» 16+
19.00 «ИГРА В СУДЬБУ» 16+
23.15 «Порча». «Красные слёзы». «Хранитель» 16+
00.20 «Знахарка» 16+
00.50 «Верну любимого» 16+
01.20 «Понять. Простить» 16+
02.10 «ВОСТОК-ЗАПАД» 16+
03.00 «Тест на отцовство» 16+
04.40 «Давай разведёмся!» 16+
05.30 «6 кадров» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «СЧАСТЬЕ ТЫ МОЕ». 7-я и 8-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.25 «ОШИБКА РЕЗИДЕНТА». «ПО СТАРОЙ ЛЕГЕНДЕ» 12+
11.00, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ВОЕННАЯ РАЗВЕДКА. ПЕРВЫЙ УДАР». Фильмы 1-й и 2-й 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Предвидение космоса». Документальный сериал. «Реактивный прибор». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века». Документальный сериал. «Юрий Шевченко. Живописец разведки» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.55 «ДВЕ ВЕРСИИ ОДНОГО СТОЛКНОВЕНИЯ» 12+
02.30 «Мария Закревская. Драматургия высшего шпионажа». Документальный фильм 12+
03.25 «ВОЕННАЯ РАЗВЕДКА. ПЕРВЫЙ УДАР». Фильм 1-й 16+

1 ноябрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телесериал 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». Телесериал 16+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «БЕРДӘНБЕР» (Татар телендә) 16+
13.00 «Родная земля» (Татар телендә) 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – ЦСКА. Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Константин Васильев. Образ жизни 12+
00.45 «Каравай». От народной музыки до короля инструментов – органа 6+
01.15 «Татар теле дәресләре» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Ватандашлар». Мөнир Ерзин. Хәтер утта янмас 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Сара Садыйкова турында телеочерк 6+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Большая премьера. «ТРИГГЕР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Андрей Смоляков, Александр Горбатов, Марина Александрова, Дарья Урсуляк, Сергей Газаров, Кирилл Зайцев, Александр Устюгов, Виктор Добронравов, Андрей Мерзликин, Филипп Ершов, Агриппина Стеклова, Светлана Колпакова. «ХУДОЖНИК» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
03.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.20, 16.50, 19.50 Новости
07.05, 16.05, 19.55, 01.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00 Специальный репортаж 12+
10.25 Еврофутбол. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20, 04.00 «Катар. Обратный отсчёт» 12+
14.25 Дзюдо. Чемпионат России. Прямая трансляция из Екатеринбурга
16.55 Гандбол. Seha-Газпром Лига. «Пермские медведи» (Пермь) – «Чеховские медведи» (Московская область). Прямая трансляция
18.35 Karate Combat 2022. Трансляция из США 16+
20.30 Футбол. Лига чемпионов. «Порту» (Португалия) – «Атлетико» (Испания). Прямая трансляция
22.45 Футбол. Лига чемпионов. Прямая трансляция
01.55 Футбол. Лига чемпионов 0+
03.55 Новости 0+
05.00 «Правила игры» 12+
05.30 «Наши иностранцы» 12+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. «БАЛАБОЛ» 16+
22.10, 00.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» 16+
00.30 «Основано на реальных событиях» 16+
02.05 Сериал «ЗВЕРОБОЙ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.25 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Осколки» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.20 «Верну любимого» 16+
14.55 «ОСКОЛКИ СЧАСТЬЯ 2» 16+
19.00 «УРОКИ ЖИЗНИ И ВОЖДЕНИЯ» 16+
22.45 «Порча». «Детский вопрос». «Черная душа» 16+
23.50 «Знахарка» 16+
00.25 «Верну любимого» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.45 «ВОСТОК-ЗАПАД» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.05 «6 кадров» 16+
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.10 «ВОЕННАЯ РАЗВЕДКА. ПЕРВЫЙ УДАР». Фильм 2-й 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 23.25 «ОШИБКА РЕЗИДЕНТА». «ВОЗВРАЩЕНИЕ БЕКАСА» 12+
10.50, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ВОЕННАЯ РАЗВЕДКА. ПЕРВЫЙ УДАР». Фильмы 3-й и 4-й 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Предвидение космоса». Документальный сериал. «Граждане Вселенной». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
00.45 «ПЕРЕД РАССВЕТОМ» 16+
02.10 «ЗЕЛЕНЫЙ ОГОНЕК» 12+
03.25 «ВОЕННАЯ РАЗВЕДКА. ПЕРВЫЙ УДАР». Фильм 3-й 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 31 ОКТЯБРЬ – 6 НОЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Тормышыгызның яхшыра баруын күреп сөенерсез. Күңелле яңалыклар, дус-ишләрегез белән җылы очрашулар, романтик рухтагы күрешүләр көтегез. Кыскасы, эштә дә, өйдә дә, күңелдә дә – тәртип.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Тирәгездәгеләрдән 100 процентка бирелеп эшләүләрен таләп итмәгез. Аларны дустанә җылы караш, тәмле сүз белән рухландырырга кирәк хәзер. Шулай гына барысы да җайлы барачак.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Тормышыгызның барлык өлкәләрендә уңыш киң итеп елмаерга тора. Эштәге кыенлыклардан котылып калачаксыз, сөйкемлелек белән кемнәрнеңдер башын әйләндерәчәксез, акчагызны исктиткеч дәрәҗәдә дөрес һәм бәрәкәтле тотачаксыз. Җыеп кына әйткәндә, үзегезне иң бәхетле кеше кебек хис итәчәксез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Бердәнберегезнең ярдәменә таянып, зур эшләр башкарырсыз. Тормышыгызның төрле өлкәләрендә күңелгә сары май булып ятардай көтелмәгән хәлләр килеп чыгасын белеп торыгыз. Бары тик кемнәрнеңдер килделе-киттеле киңәшләрен генә тотмагыз.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Башкаларның эшенә тыгылмагыз – начар булып сез калачаксыз. Игътибарны үз бурычларыгызны үтәүгә, көндәлек мәшәкатьләрне башкаруга гына юнәлтегез. Иң күңеллесе – матди хәлегезнең яхшыруын көтегез.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Эштә ныклык, үҗәтлек күрсәтергә кирәк. Моңа ирешелсә, җитәкчегездән мактау сүзләре ишетү генә түгел, саллы гына премия дә алырсыз. Иң мөһиме – тырыш һәм намуслы булыгыз.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Ике киңәшне тотсагыз, уңышка ирешәчәксез. Беренчедән, үзегезгә күпне йөкләмәгез – булдыра алмавыгыз бар. Икенчедән, эш вакытын шәхси вакыт белән бутамагыз, юкса...

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Кеше арасына ешрак чыгыгыз, дип киңәш бирмәкче йолдызлар. Яңа танышларыгыз пәйда булып, сезгә алар зур файда китерәчәк. Моңа үзегез үк бик тиздән ышаначаксыз!

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Кемнәр беләндер тормыш тәҗрибәсе урталашырга туры килер. Бу исә күңел күтәренкелегенә китерер. Бердәнберегез матур яңалыклары белән куандырыр. Атна ахырында кесәгезгә саллы гына күләмдә акча керер.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Күңелегез ниндидер үзгәрешләр тели сыман. Аңа төрле ысуллар белән ирешергә мөмкин. Гап-гади юлны сайларга – өс-башны алыштырудан башларга!

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Азга гына бала ролендә булып алыгыз. Ваемсызракка әйләнеп, тормыш агышына тулысынча бирелегез. Бераз ял итеп, көч җыю өчен шулай кирәк.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Инде онытылып ук бетә язган планнарыгыз кылт кына искә төшәчәк. Ни гаҗәп: алар эһ иткәнче тормышка да ашып куячак. Дусларыгыз арасыннан берсе үзегезне татлы уйларга этәрәчәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

БОРЫННАН БАШЛАНА

Вируслы авырулар баш калкыткан чорда борынга томау төшү – киң таралган күренеш. Ахыргача дәвалап бетермәсәң, ул борын куышлыгы ялкынсынуга (гайморит) ук китерергә мөмкин. Вакытында чарасын күрмәсәң, анысы тагын да куркынычрак, дип кисәтә белгечләр. Гайморит турында без нәрсәләр белеп торырга тиеш?

Табиб-отоларинголог Айгөл ГАЗИЗОВА шул хакта сөйләде.

НИДӘН ГЫЙБАРӘТ?

Гайморит – борын куышлыгының ялкынсынуы. Ул, гадәттә, салкын тигәндә дөрес дәваланмаган яки тиешенчә дәваланып бетмәгәндә пәйда була. Хроник гайморит борын куышлыгында сыекча тулган шеш (киста), полип булганда, борын бүлгесе кәкрәйгән очракта барлыкка килә. Тешләрен дөрес тәрбияләмәгән, вакытында дәваламаган кешеләр дә еш кына гаймориттан интегә.

БИЛГЕЛӘРЕ НИНДИ?

Гайморит вакытында кеше маңгай өлешендә баш авыртудан зарлана. Иелгәндә, борыннан яшел-сары, куе, үлекле бүлендекләр чыга. Алардан сасы ис тә килергә мөмкин. Гайморит вакытында борынга томау төшү, тыңкышлану, борын шешү кебек билгеләр дә күзәтелә. Хроник гаймориттан интегүчеләрдә бу билгеләр өч айга бер тапкыр кабатланып тора.

НИЧЕК ДӘВАЛАРГА?

Гайморитның кискен, хроник, вируслы, бактериаль, гөмбәле төрләре билгеле. Аларны дәвалау ысуллары бер-берсеннән аерыла. Дөрес дәваламаган очракта бер төрдәге гайморит икенче төрлегә әверелә ала. Әйтик, үз белдегең белән дәваланган очракта бактериаль гайморит вируслыга әйләнә. Шуңа күрә аны табиб белән киңәшләшеп кенә дәваларга рөхсәт ителә. Сүз уңаеннан, әгәр гайморит борындагы киста аркасында барлыкка килсә, аны алып атмыйча, чирдән котылып булмаячак.

КОРОНАВИРУСТАН СОҢ ӨЗЛЕГҮ БУЛА АЛАМЫ?

Юк, гайморит белән коронавирус арасында бернинди бәйләнеш тә юк.

МУНЧА КЕРЕРГӘ ЯРЫЙМЫ?

Гайморит вакытында мунча керергә ярый. Әмма борынны тоз, ингаляция кебек ысуллар ярдәмендә җылытырга ярамый. Болай эшләгәндә чир азып, ялкынсыну тагын да көчәячәк.

БОРЫН КУЫШЛЫГЫН ТИКШЕРҮ КУРКЫНЫЧМЫ?

Гайморит вакытында бер тапкыр борын куышлыгын тиштерсәң, аны гел тиштереп торасы булачак, дигән фикер яши. Әмма бу – уйдырма. Безнең белгечлек табибларының үзегенә үткән мәсьәлә бу. Беренчедән, без бу тишемне сөякнең иң нечкә урынында ясыйбыз. Бер айдан инде аның эзе дә калмаячак. Вакытында тишмәсәң, сулыш юлы белән борын куышлыгы арасында җыелган үлек шул урында тыгызланып тупланачак. Нәтиҗәдә хроник гайморит пәйда булачак.

ТОМАУ ТӨШКӘНДӘ, КАН ТАМЫРЛАРЫН КИҢӘЙТӘ ТОРГАН ТАМЧЫ, СПРЕЙЛАР КУЛЛАНУ НӘРСӘСЕ БЕЛӘН КУРКЫНЫЧ?

Организм аларга бик тиз ияләшә. Алар, иң беренче чиратта, энә шул яктан куркыныч тудыра. Шуңа күрә мондый спрей, тамчыларны 5–7 көннән дә артыграк кулланырга ярамый.

Гайморитны кисәтү өчен табиб киңәшләре

1. Салкын тию, грипп кебек авыруларны йоктырган очракта тиешенчә, ахыргача дәваланып бетегез.
2. Даими рәвештә теш табибына барып, кариес, казналык авыруларын вакытында дәвалап торыгыз.
3. Тузанлы, коры һавалы урыннардан читтә булыгыз.
4. Иммунитетны ныгыту өчен, сезонлы яшелчә, җиләк-җимеш ашагыз.
5. Инфекцияле чирләр котырган чорда кеше күп җыелган урынга чыкканда, битлек киярга онытмагыз.
6. Көн дәвамында чиста су эчү дә файдалы. Ул борын куышлыгының лайлалы тышчасын дымландырып торырга ярдәм итә.

Тәмле дәва

Лимон белән дуслашыр чак

Ангина. Бу вакытта телемләп киселгән лимонны авызга кабып суырырга һәм йотарга, моны сәгать саен кабатларга киңәш ителә. Бигрәк тә лимонның кабыгы файдалы. Аны чәйнәгәннән соң, С витамины тамак төбендәге бактерияләрне үтерсен өчен, башка ризык капмый торырга кирәк.

Ютәл. Тигез күләмдә бал, лимон согы, шикәр комы кушып кайнатырга да, өянәк башлангач, 1 аш кашыгы күләмендә кабып куярга кирәк.

Вирусларга каршы чөгендер һәм лимон согы кушылмасы – иң яхшы чара.

Гипертониядән интегүчеләргә тәүлегенә 3–4 тапкыр кабыгы белән ярты лимон ашарга.

Баш авыртканда, лимон кабыгының ак элпәсен чистартып, юеш ягы белән чигәгә куеп, берникадәр вакыт тотарга. Озакламый лимон кызарып чыгар, ә башыгызның авыртуы бетәр.

Күңел болганганда, лимонның кабыгы белән йомшагы арасындагы ак элпә ярдәмгә килә. Косасы килгәндә, берараз гына баллы лимонлы су эчеп, сохари ашап куярга кирәк.

Яхшы ишетү өчен дә лимон кулланыла. Моның өчен көнгә 1/4 лимонның кабыгын ашау да җитә.

Йөрәк, кан тамырларын ныгытабыз. Лимонда витаминнар, бик кирәкле микроэлемент – калий да бар. Ул җимеш составындагы цитрин һәм аскорбин кислотасы белән кушылып, нечкә кан тамырларының стеналарын ныгыта, аларның сыгылмалылыгын арттыра.

Көзән җыерганда, 10 көн дәвамында иртә-кич аяк табанын лимон согы белән ышкырга. Согы кипкәч, оекбаш киярга.

Борын канаганда, борын тишегенә лимон согы сеңдерелгән мамык тыгарга кирәк. Кан нык ага икән, борын яфракларын бармаклар белән кысып, 3 минут тотарга. Белгечләр бу вакытта маңгайга юеш салкын сөлге яки боз куеп торырга киңәш итә.

Ә сез беләсезме?

КҮЗЛӘРГӘ ФАЙДАЛЫ

Өлкән яшьтәге кешеләр арасында күзнең челтәр катламы дистрофиясе еш очрый. Моны кисәтү өчен, канда лютеин югары дәрәҗәдә булырга тиеш. Әлеге элемент исә йомырка сарысында күп. Шуңа күрә табиблар өлкән яшьтә дә күзләр яхшы күрсен өчен, көн саен 1 йомырка ашап куярга киңәш итә.

Бавырга да, канга да шифа

Кызыл миләшнең шифасы әйтеп бетергесез. Кызыл миләштә С һәм К витаминнары, микроэлементлар күп. Анда шулай ук каротин һәм Р витаминнары бар.

Аның согын атеросклерозны һәм гипертоник авыруларны дәвалау өчен файдаланалар. Миләш төнәтмәсе эч йомшарту өчен дә әйбәт. Ашказаны, эчәк авырулары вакытында аннан төнәтмә ясап эчәргә киңәш ителә. Миләш согы бөердән ташларны чыгару өчен дә файдаланыла. Табиблар шикәр чире белән интегүчеләргә, бавыры авыртканнарга да миләш ашарга куша.

Азканлылыктан. Ике аш кашыгы кызыл миләш җимешен ике стакан кайнар суга салып, бер сәгать төнәтеп торгач сөзәргә. Шуны көн буена өч-дүрт тапкыр аз-азлап эчәргә кирәк.

Үт куыгы ялкынсынган (холецистит) кешеләр дә миләш согының файдасын күрә. Халык медицинасында ул кан басымын нормада тоту өчен дә кулланыла. Моннан тыш кызыл миләшне изеп, шикәр комы һәм кайнар су белән болгатып, йоклар алдыннан эчү дә файдалы.

Миләш согы. Аны ясау өчен 400 г миләшне изеп, аңа 2 литр кайнаган су һәм берәз шикәр комы салырга, дүрт сәгатьтән соң болгатып, сөзеп эчәргә кирәк. Эч катканда берничә атна буена көнгә өч тапкыр 70–100 грамм шундый сок эчәргә киңәш ителә.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ИХ, КӘБЕСТӘСЕ!

Бакчадагы соңгы уңыш – кәбестә дә җыелып бетте. Быел анысыннан да бик уңдык. Ләкин мул уңышны җыеп алу гына түгел, аны саклыйсы, эш итәсе дә бар. Һәвәскәр бакчачы Әлфинур Нәҗметдинова кәбестә саклау һәм әзерләү буенча киңәшләрен бирде.

vk.com

Киптерәбез

Әлфинур ханым әйтүенчә, язга кадәр шикәр кебек саклансын өчен, кәбестәне кучәне белән җыярга кирәк. Болай эшләгәндә, яшелчәнең сусыллыгы югалмый. Саклауга куйганчы, кәбестәләрне 7–12 көн дәвамында җиләсрәк урында (әйтик, сарай яки верандада) тотарга кирәк. Бу кадәресе кайбер бакчачылар игътибарыннан төшеп кала һәм шуңа күрә яшелчә бик тиз череп әрәм була. Шуннан соң инде аларның кайсыларына черек керүен яки бөҗәкләрдән зыян килүен өске яфракларыннан җиңел генә күрергә мөмкин, ди бакчачы. Аннан инде баш киштәсенә уртача зурлыктагыларын төшереп куярга мөмкин. Артык эре булмаган башларның сусыллыгы да, тәме дә әйбәтрәк саклана. Калганнарын тозлап, маринадлап куярга яки аш-су өчен кулланырга була.

Газетага төрәбез

Тәҗрибәле бакчачы сүзләренә караганда, кәбестәне киштәләргә урнаштырганчы, баздагы дымлылык дәрәҗәсен тикшереп карау кирәк. Күрсәткеч 75 процентка җитәргә тиеш. Моннан кимрәк икән, 3 литрлы банкаларга су тутырып куярга мөмкин. Базның җилләтелүе дә мөһим. Температураның исә 2–5 градус җылы булуы әйбәт. Кәбестәләрнең һәркайсын газетага яки азык-төлек пленкасына төреп (пленка белән һава кермәслек итеп, тыгызлап төрергә), киштәләргә яки агач тартмаларга бер-берсенә тиеп тормаслык итеп урнаштырырга кирәк. Кольраби кәбестәсен (шалкан кебек була) комга күмеп сакларга була. Пекин кәбестәсен бары тик пленкага төреп, өч ай гына сакларга мөмкин.

Әлфинур ханым кәбестәне кышка әзерләүнең бик күп ысулын белә. Аның кайбер рецептларын сезгә тәкъдим итәбез.

Алма белән кәбестә тозлау

Кирәк: *1 литрлы банкага 600–700 грамм кәбестә, 2 яшел алма, 1 эре кишер, 2 дәфнә яфрагы, 2 хуш исле түгәрәк борыч, 2 канәфер, 4 түгәрәк кара борыч, 1 аш кашыгы тоз, 1 аш кашыгы шикәр комы.*

Кәбестәне, саламлап, нәзек кенә итеп турыйбыз. Кишерне уртача зурлыктагы тишекле угыч аша чыгарабыз. Барысын да зур савытка тутырып, тоз һәм шикәр комы өстибез. Болгатабыз. Кәбестәнең суы чыксын өчен, 30 минут тотабыз. Алманы юып, 4–6 кисәккә бүләбез. Кишерле кәбестәне чиста банка төбенә тыгызлап салабыз. Хуш исле һәм кара борыч, дәфнә яфрагы, канәфер нормасының яртысын, берничә кисәк алма өстибез. Тагын кишерле кәбестә катламын, тәмләткечләрне, алма кисәкләрен урнаштырабыз, суы чыксын өчен, әйбәтләп тыгызлыйбыз. Банка өстенә капрон капкач куеп (япмаска), бүлмә температурасында 3 тәүлек тотабыз. Капкачны һәр көн саен ачып, һавасын чыгарабыз; агач таякчыкны банка төбенә кадәр төшереп, кәбестәне тишкәлибез. 4 нче көнне, банканы капкач белән каплап, суыткычка куябыз.

Чөгендер белән кәбестә маринадлау

Кирәк: *2 кг кәбестә, 1 эре кызыл чөгендер, 2 кишер, 2–3 тырнак сарымсак, 1 литр су, 120 грамм шикәр комы, 100 мл үсемлек мае, 150 мл 9 процентлы серкә, 2,5 аш кашыгы тоз, 4–5 түгәрәк борыч, 2–3 дәфнә яфрагы.*

Кәбестәне салам рәвешендә турыйбыз. Кишер һәм чөгендерне юып чистартып, эре тишекле угыч аша чыгарабыз. Яшелчәләрне, барысын бергә болгатып, чиста банкаларга тутырабыз. Маринад әзерлибез: кәстрүлгә су агызып, шикәр комы һәм тоз, дәфнә яфрагы һәм борыч салабыз. Утка куеп, кайнатып чыгарабыз. Кайнап чыгар алдыннан үсемлек мае һәм серкә өстибез. Әйбәтләп болгаткач, уттан алабыз. Кайнар маринадны яшелчәле банкаларга агызабыз. Капкач белән каплап, суынганчы, бүлмә температурасында тотабыз. Банкаларны 24 сәгатькә суыткычка алып куябыз. Кетердәп торган искиткеч тәмле кәбестә әзер!

Татлы борыч белән кәбестә маринадлау

Яртышар литрлы өч банка өчен кирәк: *1 кг кәбестә, 2 кишер, 1 эре татлы борыч, 1 баш суган, 3–4 тырнак сарымсак, 2 аш кашыгы тоз, 5 аш кашыгы шикәр комы, ярты чәй кашыгы төелгән кара борыч, 2 дәфнә яфрагы, ярты чәй кашыгы төелгән татлы паприка, ярты чәй кашыгы төелгән кызыл борыч, 1,5 аш кашыгы серкә эссенциясе (70 процентлы), 7 аш кашыгы үсемлек мае.*

Кәбестәне саламлап турыйбыз. Кишерне уртача зурлыктагы тишекле угыч (иң яхшысы – корейча кишер угычы) аша чыгарабыз. Кәбестәгә кишер, тоз, шикәр комы, төелгән борычның барлык төрләрен, дәфнә яфрагын салып болгатабыз. Суы чыксын өчен, 20 минутка калдырабыз. Татлы борычны салам рәвешендә турыйбыз. Кәбестәгә өстәп, яхшылап болгатабыз. Ярымбоҗра рәвешендә туралган суганны, таба төбенә май салып, алтынсу төскә кергәнче кыздырабыз. Изелгән сарымсак өстибез, болгаткач, уттан алабыз. Майлы суган һәм сарымсак катнашмасын кәбестәгә салабыз. Серкә эссенциясен өстәп, яхшылап болгатабыз. Кәбестәне парландырылган банкаларга тыгызлап тутырабыз да, капкач белән каплап, «су мунчасы»нда 15 минут тотабыз (1 литрлы банка өчен 20 минут вакыт кирәк). Шуннан соң капкач белән борып ябабыз һәм салкынча урында саклыйбыз.

Белеп тор!

КАМЫР РИЗЫГЫ ӘЗЕРЛӘҮ СЕРЛӘРЕ

✓ Бәлеш-бөккәннәр авызда эреп торсын өчен, камырына йомырканың сарысын гына (агын башка максатта кулланырга мөмкин) өстәргә кирәк.
✓ Камырга маргарин салган очракта, тозны әзрәк өстисе.
✓ Төче камырга бераз крахмал өстәгәндә, ризык бик йомшак була, кетердәп тора.
✓ Ризыкны газ миченә куйгач, беренче 10 минут эчендә ишеген ачып карарга ярамый: юкса камыр шәлперәячәк.
✓ Пешкән ризыкны бераз суынгач кына табадан алыгыз, юкса формасы югалачак. Шул ук вакытта анда озак тотарга да ярамый: дымланып, тимер исен сеңдерәчәк.

Какао һәм кына хикмәте

Агарган чәчләрне буяу өчен «химия» белән маташасыгыз килмиме? Бу очракта какао һәм кына (хна) ярдәмгә киләчәк. Бер кап кынага 1 аш кашыгы какао (кабындагы инструкциясе буенча әзерләп) өстәп болгатыгыз. Катнашманы чиста чәчкә сылап, 4–5 сәгать тотыгыз, тәнгә калдырырга да мөмкин.

Башны югач, ак чәчләрнең эзе дә калмавын күреп сөенәчәксез! Мондый буяудан соң чәчләр ялтырап, күпереп, сәламәтләнеп китәчәк.

Укучы киңәше

Алма серкәсе ясыйбыз

Чистартылмаган алма серкәсенең искитмәле әйбер булуын беләсезме икән? Алманың бөтен файдасы шунда! Ләкин сатуда мондый серкәне табып булмый, сәүдә киштәләрендә – бары тик чистартылганы гына. Аны мин үзем ясыйм.

Серкә әзерләү өчен алманың хәтта коелганы да ярый. Юмаска, бары тик дымлы чүпрәк белән сөртеп кенә алырга. Җимештә әчүгә ярдәм итәрдәй гөмбәчекләрнең сакланып калуы өчен кирәк бу. Алманы орлыклары белән бергә ваклыйбыз: угыч яки иттарткыч аша чыгарабыз, яисә пычак белән шакмаклап турыйбыз. Вакланган җимешне өч литрлы банкага тутырабыз һәм шуңа су агызабыз. Су алмадан 1,5–2 см чамасы өскә чыгып торырга тиеш. Шул ук вакытта банканың чама белән өчтән бер өлеше буш калсын. Әчегән вакытта күләме арта.

Төгәлрәк әйтсәк, 3 литрлы банкага, шакмаклап туралган очракта, 1,3 кг алма һәм 1 литр су кирәк. Тизрәк әчесен өчен, 3 литрлы банкага 50–100 грамм чамасы шикәр комы өстисе. Әчкелтем алмага ул күбрәк кирәк. Бик нык өлгергән җимешкә шикәр кушмаска да була: берәр аш кашыгы бал һәм берничә бөртек виноград өстәсәң, шул җитә. Шуннан банканың өстен чүпрәк белән каплап, караңгы, җылырак урынга (+25…+30 градус булганда тизрәк әчи) куям. Өч атнага кадәр тотам (җылырак урында ике атнадан соң да өлгерә). Шушы вакыт эчендә аны һәр көн саен берәр тапкыр болгатып торырга кирәк. Әчүдән туктагач, сөзеп, серкәне чиста савытка бушатам да караңгы урынга алып куям. Монысы – әчетүнең икенче этабы. Савыт төбендә утырма хасил булып, сыекча үтә күренмәләгә әйләнгәнче дәвам итә ул. Моның өчен 1,5–2 ай вакыт кирәк. Бу чорда банканы тынычлыкта калдырам. Шуннан соң серкәне тагын бер кат сөзәм (капрон оек аша бик әйбәт сөзелә) дә, чиста шешәгә тутырып, караңгырак урынга алып куям. Аны ярты елдан соң куллана башлау әйбәт. Шушы вакыт эчендә серкә тулысынча өлгереп җитә һәм бөтен файдалы матдәләрен туплый. Шунысын да әйтеп үтим: саклаганда, серкә өстенә койкасыман элпә җыелырга мөмкин. Серкәнең бик дөрес ясалганын күрсәтә торган билге бу. Аны алып ташламагыз, ә серкә урынына кулланыгыз.

Светлана БИКБУЛАТОВА.
Казан

МӘХӘББӘТ НИКАХТАН СОҢ КИЛӘ

Кешелек яралганнан бирле, мәхәббәт төшенчәсен ничәмә-ничә галим, җырчы, шагыйрь, рәссам үзенчә аңлатырга тырышкан. Бу хисккә карата динебездә нинди караш икән? Гашыйк булу белән чын ярату арасында аерма бармы?

Кызыксындырган сорауларга Лаеш районындагы «Ихлас» мәчете имамы Мөдәррис ГЫЙМРАНОВ җавап бирде.

:: Ислам динендә ярату, гашыйк булу турында ни диелә?

– Беренчедән, Аллаһы Тәгалә адәм баласын бу дөньяга бәхетле итәр өчен яралткан һәм күп итеп нигъмәт биргән. Шулар арасында парлы булып, гаилә корып яшәү бар. Ислам дине мәхәббәткә, гаилә мәсьәләсенә бик зур урын биргән. Атабыз Адәмгә (г.с.) күңелсез булган вакытта, Раббыбыз аңа анын кабыргасыннан Һава (р.г.) анабызны бар кыла. «Рум» сүрәсенең 21 нче аятендә Аллаһы Тәгалә әйтә: «Бер-берегездә тынычлык табу өчен, мин сезне бер атадан яраттым, арагызга мәхәббәт һәм рәхим-шәфкать урнаштырдым».

Боларны Аллаһы Тәгалә ир белән хатынга карата әйтә. Мәхәббәт никахтан соң килә, дибез. Никахка кадәр ул – гашыйк булу, гыйшык тоту. Хәзерге көндә, кызганыч, гыйлемнәребез сай булу сәбәпле, гаилә тормышына әзерләү юк. Булса да, дөрес булмаган формаларда, юнәлешләрдә.

Ир белән хатын булганчы, егет белән кызның мөнәсәбәтләре бер катлы гына була. Чәчәк, очрашып йөрүләр, яратам, синнән башка яши алмыйм һәм башкасы... Ә никах корып, гаилә булып яши башлагач, икесенең дә моңа кадәр ачылмаган яклары пәйда була. Яшереп килгән холыклар да ачыла. Бер тәүлектә – 24 сәгать, елда – 365 көн, тапкырласак, 8760 сәгать килеп чыга. Бу сәгатьнең бер өлеше эштә, тегендә-монда үтә, ди. Әйтик, 6000 сәгатьне бергә уздыра башлагач, күп нәрсәләргә ачыклык керә. Бу вакытта инде сабырлык кирәк булыр. Шуңа күрә егет белән кызның бәхетле тормышка ишеге – никах. Никахлашудан соң гына бирелә торган бүләк бар – мәхәббәт. Бүген ул төшенчәнең бәһасе төште. Ә бит ул арзан хис түгел!

:: Сөекле пәйгамбәребез (с.г.в.) хатыннарына карата нинди мөнәсәбәттә булган?

– Рәсүлебезнең (с.г.в.) холкы турында сорагач, аның холкы Коръән иде, дигәннәр. Ул хатыннарына карата бик күркәм булган. Андый мөнәсәбәт бүген юк! Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) тәрбиясе шундый булган. Ә аның тәрбиячеләре – Аллаһы Тәгалә һәм Җәбраил (г.в.). Ятим булып үсеп тә, нинди бөек дәрәҗәгә җитә бит ул! Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Сезнең иң хәерлегез гаиләсенә хәерле мөнәсәбәттә булганы», – ди. Пәйгамбәребез (с.г.в.) кием-нәрен дә ямаган, идәнен дә себергән, хатыннарына да булышкан. Йомшак күңелле, ярдәмчел булуы шуннан да күренә. Алайса, хәзер ир дә, хатын да эштән арып кайта, әмма никтер ир диванда ята, хатын исә ашарга пешерергә, йортҗир эшләрен башкарырга тотына. Икең бергә булырга тиеш. Күрше кереп булышмас бит инде хатыныңа.

Ольга Орехова

:: Егет белән кыз өйләнешкәнче ничек аралашырга тиеш?

– Алар шаһитлар янында очрашырга тиеш. Рәсүлебез (с.г.в.) хәдисендә: «Чит ир һәм чит хатын икәүдән-икәү калмасын. Өченчегез шайтан булыр. Ә аның максаты – адәм баласын туры юлдан яздыру», – дип әйткән. Аллаһы Тәгалә дә, карашларын кирәкмәгән нәрсәләргә караудан һәм җенси әгъзаларын зинадан саклсын, дип әйтә Коръәндә. Караш белән җенси әгъзаны бер аятькә кертеп бәйләү юкка түгел. Барысы да караштан башлана. Шәһвәт туа. Уй килә. Аннан исә шуны тормышка ашыралар.

Егет белән кыз кеше булган урында очрашсыннар. Бу бит әти һәм әни өчен дә мөһим. Кызлары булган ата-аналар өчен аеруча да! Кызың, балаң кайда, кем белән йөри? Җәмгыятьнең төзеклеге өчен дин бу мәсьәләгә зур игътибар бирә.

Уен-көлке, шаяру, куллану, файдалану өчен генә очрашулар күбәйде хәзер. Рәсүлебез әйтә: «Кәләшне дүрт сыйфатына – нәселенә, матурлыгына, байлыгына һәм әдәп-әхлагына, диненә карап сайлыйлар. Кем соңгысына карап сайлый, шул ота. Чөнки чибәрлек китә, нәсел корый, ә әдәп-әхлак кыяммәттә дә үлчәүдә иң авыр әйбер була».

:: Элек булачак ярны ата-ана сайлаган. Хәзер мондый күренешләр юк диярлек. Бу йола дөрес булганмы?

– Бик дөрес булган! Бүген торып карыйк әле дип яшәүчеләр күп. Адәм баласы психологик яктан – катлаулы зат. Аны өйрәнеп бетереп тә булмый. Безне үзгәртергә тырышкан сәбәпләр күп. Минем практикамда шундый хәл булды. Бер абзый сөйли: сеңлем берәү белән яши, өй ашы дигән булып, сәбәп табып, аны һәм әти-әнисен дәштек, ди. Нинди нәсел, кемнәр икәнен белешер өчен шулай эшләгән. Кыз кемгә бара, ул кемгә әләгә – бу мәсьәләләр дә бар бит. Без исә кафе-ресторан, тамада, уеннар, чакыру кәгазьләренә генә күбрәк өстенлек бирәбез. Асылына исә черки кадәр дә игътибар итми башладык. Бу мәҗлеснең ахыры күңелле бетмәде. Егетнең яңа яклары ачылды. Өлкәннәрдә тәҗрибә һәм акыл бар. Алар сүзенә таянырга кирәк.

:: Хәзрәт, мәхәббәтне ничек аңлатырга?

– Мәхәббәт гаилә тормышыннан башка була алмый. Аллаһы Тәгалә мәхәббәтне бүләк итеп бирә. Гыйшык тоту теге яисә бу сыйфатларга карата булырга мөмкин. Тәс-кыяфәт, фигура, йөз... Бу – нәфес уены гына. Бу – шәһвәт, әмма мәхәббәт түгел!

Мәхәббәтне сатып алып булмый. Әгәр дә 10 кешенең унысына да унар миллион сум акча бирсәң, һәркайсы бу малны төрлечә тотачак. Кемдер бер көндә, кайсысыдыр бер-ике атнада, кемдер берничә елда. Ә берәве шул 10 миллионны дөрес кулланып, арттырырга мөмкин. Мәхәббәттә дә шулай. Гаиләң, балаларың, ярың, Аллаһ хакына тырышырга кирәк. Ир белән хатын арасында тырышлык бетә. Гаилә коргач, бер-береңә матур сүзләр әйтү, бүләкләр бирү, матур итеп киенү, ислемайлар сөртү кебек вак кына тырышлыклар да бетәргә тиеш кебек кабул ителә бугай. Әлбәттә, сүзсез дә аңлашкан кешеләр бар. Бер калыпка салып үлчәмибез. Әмма гомум кагыйдәләр бар бит. Гаилә тормышында әнә шул серле тырышлык бетмәсен иде. Шулар якынайта. Рәсүлебез дә: «Бер-берегезгә бүләк бирешегез, ул сезнең арадагы мәхәббәтне арттырыр», – дигән. Тормыш мәшәкатенә чумып, мактау, ягымлы сүзләр әйтүне онытып җибәрмәсәк иде. Аздан да күңел була, юктан да хәтер кала бит.

Ноябрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Сиш	04:43	06:49	14:11	16:04	17:48
2	Чәрш	04:45	06:51	14:09	16:02	17:46
3	Пәнҗ	04:46	06:53	14:07	16:00	17:44
4	Җом	04:48	06:55	14:05	15:57	17:43
5	Шим	04:50	06:57	14:03	15:55	17:41
6	Якш	04:52	06:59	14:01	15:53	17:39
7	Дүш	04:53	07:01	13:59	15:51	17:38
8	Сиш	04:55	07:03	13:58	15:49	17:36
9	Чәрш	04:57	07:05	13:56	15:47	17:34
10	Пәнҗ	04:59	07:07	13:54	15:46	17:33
11	Җом	05:00	07:10	13:52	15:44	17:31
12	Шим	05:02	07:12	13:51	15:42	17:30
13	Якш	05:04	07:14	13:49	15:40	17:28
14	Дүш	05:05	07:16	13:47	15:38	17:27
15	Сиш	05:07	07:18	13:46	15:37	17:26
16	Чәрш	05:09	07:20	13:44	15:35	17:24
17	Пәнҗ	05:10	07:22	13:43	15:33	17:23
18	Җом	05:12	07:24	13:42	15:32	17:22
19	Шим	05:14	07:26	13:40	15:30	17:21
20	Якш	05:15	07:28	13:39	15:29	17:20
21	Дүш	05:17	07:30	13:37	15:27	17:19
22	Сиш	05:18	07:32	13:36	15:26	17:17
23	Чәрш	05:20	07:34	13:35	15:24	17:17
24	Пәнҗ	05:21	07:36	13:34	15:23	17:16
25	Җом	05:23	07:37	13:33	15:22	17:15
26	Шим	05:24	07:39	13:32	15:21	17:14
27	Якш	05:26	07:41	13:31	15:20	17:13
28	Дүш	05:27	07:43	13:30	15:19	17:12
29	Сиш	05:28	07:45	13:29	15:17	17:12
30	Чәрш	05:30	07:46	13:28	15:17	17:11

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Белеп тор!

- Дөньяда комсыз булма, сине Аллаһ яратыр, кешеләр кулында булган нәрсәләргә кызыкма, сине халык яратыр.
- Кәсепнең иң яхшысы – хыянәтсез сәүдә һәм кешенең үз кул көче белән мал табуы.
- Бернинди нигезсез кешеләр турында яман уйлаудан сакланыгыз, чөнки начар уй – сүзләрнең иң ялганы. Кешеләрнең гаепләрен тикшермәгез, көнләшмәгез, ачуланышмагыз, бер-берегезне ташламагыз, Аллаһының коллары булган халдә бер-берегезгә кардәшләр булыгыз!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Газетабызның узган санында чыккан җырлы һәм җырларны беренчеләрдән булып Арчадан **Зөлфия Галәүтдинова** танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Винера Ганиева башкаруындагы «Мин Казанда сине эзләп таптым», Филүс Каһировның «Киек каз юллары» һәм Хәйдәр Бигичев репертуарыннан «Бөдрә таллар» җырларын яшергән идек.*

Бу җыр – адашып йөргән пар турында. Ул синең хисләр утында янганыңны күзләреңнән үк күрә, ә син сизми дип уйлыйсың.

Сөн буенда үскән агачлардан үрелгән, яшь балаларның күп вакыт үткәрә торган җайланмалары турында бу җыр.

Әлеге җыр яшьлек белән күк җисемен чагыштыра. Яшь гомерне дә, менә шул күк җисемен дә тотып калып булмый, ди җырчы.

ФӘННҮР МӨХӘММӘТҖАНОВ:

«ТОРМЫШКА КАРАШЫМ ҮЗГӘРДЕ»

Бүгенге сәхифәбезнең кунагы – Камал театры артисты Фәннүр МӨХӘММӘТҖАНОВ. Аның белән без репетициядән бушаган арада сөйләшеп алдык. Тиздән Камалда – чираттагы премьера. Мәхмүт Галәүнең Сафасы хәлендә калмас өчен безгә нишләргә? Дүрт сәгатьтән арткан спектакльдә уйнау ни дәрәҗәдә авыр? Фәннүр Мөхәммәтҗанов – нинди әти? Ир-ат өчен чын бәхет нәрсә ул? Без әнә шулар хакында сөйләштек.

:: Ни хәл?
– Хәлләр Аллага шөкер инде. Эшлибез, премьерага әзерләнәбез.

:: Премьера, дигәннән. Мәхмүт Галәү романнары буенча «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектаклен чыгарырга әзерләнәсез. Бүгенге хәлләргә аваздаш әсәр, килешәсеңме?
– Килешәм. Һәм аның авырлыгы да шунда. Бу әсәргә алынганда, дөньялар бу кадәр үк болганчык түгел иде әле. Ул чакта репетицияләр җиңелрәк бирелде. Вазгыятьтәге киеренкелек арткач, эшләү дә катлауланды. Бер миңа гына алай булмагандыр. Хәзер дөньяда барган вакыйгаларны тыңламаска тырышам. Бар игътибарымны, көчемне премьерага юнәлттем.

Ләкин дөрес аңларга кирәк: без пропаганда һәм сәясәт белән шөгыльләнмибез. Аларга сәхнәдә, гомумән, урын юк. Эшебез, хезмәтебез бөтенләй башка максатлардан гыйбарәт. Без тамашачыга сорау, уйланыр өчен җирлек бирәбез.

:: Фәннүр абый, Сафа хәлендә калмас өчен, безгә бүген нәрсә эшләргә кирәк?
– Бәхетең булса, үз илеңдә дә бәхетле буласың. Бәхетең булмаса, аны кайдан да таба алмыйсың. Беренче чиратта, шуны аңларга кирәк. Сабыр булыйк, аек акыл белән эш итик, Ходай Тәгаләдән дөньяның тынычлануын сорыйк.

:: Әле бит бу спектакльнең вакыт ягыннан күләме дә башкаларыннан аерылып тора. Актер өчен бу – шулай ук үзе бер сынаудыр?
– Әйе, анысы да бар. «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» өч акт һәм ике антрактлы спектакль булачак. Бер антракттан гына торган спектакльләрдә эмоцияләреңне, энергияңне чамалыйсың. Ә монда ничек тә ахырга кадәр «сүнмәскә», бер генә минутка да игътибарны читкә җибәрмәскә кирәк. Башыннан ахырына кадәр сәхнәдә булу, ә бу – дүрт сәгатьтән артык дигән сүз, физик яктан да, эмоциональ яктан да искиткеч зур көч таләп итә.

:: Быел җәй «Алмаш» сериалын төшердегез. Син анда төп рольне башкарасың. Гомумән, кинода төшү ошадымы? Спектакльдә уйнаудан нык аерыламы?
– Бу тәҗрибә ошады. Ләкин бик авыр булды. Кинода төшкәндә сәхнәдәге кебек җәелеп китеп уйнап булмый. Сәхнә барыбер иркен ул, анда эмоцияләр дә артыгы белән китәргә мөмкин, кул селтәүләр, хәрәкәтләр дә. Ә камера синең кирәгеннән артык күз сирпүеңне дә күреп ала. Вак кына фальш, хаталар – барысы да уч төбендәге кебек.

:: Ә синең өчен театр артисты гына түгел, кино һәм театр артисты булу мөһимме?
– Була алсаң, әйбәт инде ул. Кино – артистның театрдан тыш икмәге ул. Бу өлкәнең акчалы булуы берәү өчен дә сер түгел. Артист өчен зур тәҗрибә дә әле ул. Яхшы режиссерга эләксәң, бигрәк тә. Андый мөмкинлек булса, үземне ике өлкәдә дә сынар идем.

:: Сезнең бит быел гаиләгез ишәйде – кызыгыз туды. Фәннүр абый, ике кыз әтисе булу ничегрәк?
– Беренче чиратта, икеләтә җаваплылык ул. Икесен дә каргарга, икесенә дә тиешенчә игътибар бирергә кирәк. Минем хатыным да безнең театрда эшли бит. Хәзер монда дүртәүләп киләбез. Бер сер ачам: Фәрит абый Бикчәнтәев «Мөһаҗирләр»дә уйнарга олы кызым Сәйдәне чакырды. Икәү бергә уйныйбыз, Алла боерган булса.

:: Нинди әти син?
Яңа көн туган саен гаиләдә уйлар да, борчулар да өстәлә генә кебек. Шул ук вакытта горурлык хисләре дә ташламый аларны. Әни кеше белә: батырлык җиңел генә бирелми. Сөйләшкәндә дә сизелеп тора: йөрәгендә сөенече дә, көенече дә бергә кайный аның. Әтисе Наил полициядә хезмәт иткән, эчендәгесен тышка бик чыгармаска да күнеккәндер, мөгаен. Хәер... бала дигәндә башкача да булырга мөмкин. «Минем хатыным әйбәт сөйли», – дип, шаяру катыш әңгәмәдән читләшергә омтылуы да әнә шул хисләрне тышка чыгарырга теләмәвеннәндер, бәлки. Борчылу, һәр телефон тавышыннан сискәнеп китү, көтү – бүген Габдрахмановлар гаиләсе әнә шундый халәттә яши.

Бу халәт февраль аеннан ук башланган. Нәкъ шул вакытта Раилне укырга җибәрәләр. Бервакыт телефоннан сөйләшкәндә, ул: «Әни, син яңалыклар карыйсыңмы?» – дип сорый. Әнисе каушап кала. Үзе дә сизмәстән: «Юк», – дип җавап бирә. Шуннан соң улы: «Ярар алайса, карама», – дип әйтеп куя. Шуннан барысы да аңлашыла инде. Шул ук айда Раилне махсус хәрби операция зонасына җибәрәләр. «Шуңа укыдым бит инде. Мин Ватанны сакларга һәм якларга тиеш», – дип тынычландыра ул әнисен.

Улының Герой булуы турындагы хәбәрне ишеткән мизгелләрне искә алабыз.

– Украинада чагында ук үзе шалтыратып әйтте, – ди Лира ханым. – Яңалыкларны берсен дә калдырмыйча диярлек күзәтеп бара идек. Май аенда Раилгә Суворов медале тапшырдылар. Соңрак улым: «Хәрби заданиенең зуррагын үтәдем, әни, бүләкнең тагын да зуррагын бирерләр, ахры», – дип сөйләште. «Нинди бүләк соң ул, улым?» – дим. «Иң зурысы инде, әни, синең улың – Герой», – ди. Бик шатландык. Горурландык та. Бигрәк тә, улыбызның тырышлыгын күрә белгәннәр дип, командирларын мактадык. Ни дисәң дә, зур эшләр башкарып, игътибарсыз да калырга мөмкин бит. Үлем белән күзгә-күз карашып көрәшкәндә ташламаганнар. Рәхмәт үзләренә.

10 августта Раил Габдрахмановка Россия Герое исеме бирелә. Мәскәүдә аңа әлеге олы бүләкне оборона министры Сергей Шойгу үзе тапшыра. Шунда ике көнгә туган ягына кайтып килергә рөхсәт ала да инде ул.

– Өйгә кайтып килергә җыенуын безгә әйтмәделәр. Әмма күңелем сизде. Киленем Яна – Алтайда, улым хезмәт иткән хәрби частьта эшли. Аңа шалтыратып, уйларымны җиткердем. «И, әни, сюрприз ясарга уйлаган идек, сезне шатландырып, кинәт кенә кайтып төшәсе иде, кайдан белдегез?» – ди. Ана күңеле шулай сизгер була инде ул, дидем. Казанга төнге сәгать 2дә кайттылар. Аэропортка каршы алырга район башлыгы Александр Никошин белән бергә бардык. Ул безгә дә, улыма да бик игътибарлы булды. Рәхмәт аңа, – дип искә ала Лира ханым. – Татарстан вице-премьеры Ләйлә Фазлыева, хәрби комиссариат вәкилләре, «Халык фронты» активистлары килгән иде. Оркестрлар белән бик матур каршы алдылар. Күзләрдән яшь чыгарлык булды. Кабат Украинага киткәндә Раилне сабакташы, көрәштәше, шулай ук Россия Герое Иван Додосов белән икесен Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та кабул итте.

Йөзгә кызыллык китермәде

Раил Габдрахмановка 33 яшь, 1989 елның 11 августында Казанда дөньяга аваз сала ул. Димәк, үзенең туган көнендә менә дигән бүләк ясаган булып чыга. Аңа 4 яшь чагында әти-әнисе туган якларына кучеп кайтырга карар кыла. Йорт җиткереп керәләр. Көттерепле тагын бер уллары Фаил туа. Бүген ул Казан аграр университетында белем ала. Наил белән Лира икесе дә Әлки районының Алпар авылыннан. Бер мәктәптә, параллель сыйныфларда гына укыйлар. Шунда мәхәббәтләре чәчәк ата. Өйләнешәләр. Лира ирен армия сафларыннан көтеп ала.

– Икебез дә дәүләт эшендә тырышып эшләдек. Юклык белән яшәмәдек. Гаилә тормышы да бер тәртипкә салынган иде, – ди Лира ханым. – Шуңа күрә балаларыбыз да кыек юлга кереп китмәде дип уйлыйм.

Габдрахмановлар – Базарлы Матакта үрнәк гаилә. Наил әфәнде озак еллар районның полиция бүлегендә җинаятьчеләрне эзләү бүлеген җитәкләгән. Әлира ханым – Татарстан Казначылык департаментының Әлки территориаль бүлегендә баш хисапчы булып эшли.

«Татар-информ»

– Абыем Марат Гыйматдинов хәрби кеше иде, – дип дәвам итә ул сүзен. – Запаска чыккач, алар да Базарлы Матакка кайтып урнаштылар. Улым белән икесенең борчаклары бик пешә иде. Танк училищесына барырга да ул киңәш иткән. Чын егетләрчә булыр, дигән. Мин үзем Раилнең хәрби кеше булырга теләвен соңрак, 9 нчы сыйныфта укыганда гына белдем. Башта әйтми торуны кирәк дип санаганнардыр, күрәсең. Ә минем, ничектер, каршы килеп берәр сүз әйтергә хәтта уемда да булмады. Улымның булдырасына ышандым. Мәктәптә дә бик актив иде ул. Биюгә оста булды. Волейбол, футбол аның иң якын дуслары иде. Беркайчан да йөзгә кызыллык китермәде. Бик ярдәмчел иде. Хәтта бергә уйнап үскән күрше малайлары белән дә конфликтка кергәнен хәтерләмим. Иптәшләре дә бик ярата үзен. Әле соңгы кайтканында Гүзәл исемле сыйныфташы килгән иде. Шул искә алып торды. «Бервакыт шулай чәчәк авыруы белән чирләп ятам. Берәү урамнан, Гүзәл, Гүзәл, дип кычкыра. Тәрәзәдән карасам, Раил басып тора. Әйдә, нишләп ятасың инде, тизрәк чык, ди. Мине онытмаганнар, дип бик күңелем булган иде шул чакта. Шундый инде ул: беркемне дә игътибардан читтә калдырмады», – ди.

Бу җәһәттән киленемнең дә әлләничә тапкыр сөйләгәне бар: Раилнең кулы астында хезмәт итүчеләр аны бик хөрмәт итәләр, яраталар икән. Хатыннарына: «Командирыбыз әйбәт булгач, бездә бар да җитешле, бөтен җирдә тәртип. Башка урыннарда алай ук түгел», – дип мактаналар икән. Чыннан да, кешеләргә әйбәт бул, дип үстергән идек инде. Үзегез нинди, сезгә дә шундый мөнәсәбәт булыр, дип әйтә килдек. Хәер, юлында да гел яхшы кешеләр генә очрап торды. Сыйныф җитәкчесе, тарих укытучысы Дамир Сабитов (хәзер мәрхүм инде) артыннан бөтен сыйныфлары белән ияреп йөрделәр. Димәк, үрнәк алырлык кеше булган ул. Танк училищесында да бик яхшы белем, тәрбия биргәннәрдер дип уйлыйм. Физик яктан да, рухи яктан да ныгып, тагын да көчлерәк, үзүзенә таләпчән булып чыкты ул аннан. Укуны тәмамлагач та, Новосибирскига җибәрделәр. Нишләптер, баргач ук хезмәтитәргә урнаштыра алмадылар аларны. Иптәшләре кайтып киткән, Раил берүзе калган. «Әни, мин нишлим икән?» – дип шалтыратты. Ана кеше нәрсә әйтсен инде? Кайт, улым, дидем. Марат абыйсы, әтисе белән дә киңәшләшкән. Алар ни әйткәннәрдер, белмим. Әмма Раил ташлап китмәде. Югыйсә шул вакытта кайтып китсә, аңа беркем дә сүз әйтмәгән булыр иде. Якыннары белән киңәшләшкән сыман итсә дә, калырга дигән карарны үзе кабул иткән. Башта Новосибирскида, Кемерово хезмәт итте. Аннан Алтай төбәгендәге Алейск шәһәренә җибәрделәр. Шунда Яна белән танышып, гаилә кордылар, Осман исемле 4 яшьлек уллары бар. 2012 елда Раил, Ульяновскида хәрби база арсеналында фаҗига булганнан соң, шартламыйча калган снарядларны зарарсызландыруда катнашкан. Бу хакта мин белми дә калдым. Соңыннан гына әйттеләр.

«Борчылмагыз, барысы да әйбәт»

– Улымның гел әйтә торган сүзе бар: минем өчен борчылмагыз, барысы да әйбәт. Шундый ышандырырлык итеп әйтә ул аны, ничектер тынычланып каласың. Шунысын гына чамалыйбыз: ул һәрвакыт алгы сызыкта булды. Хәзер дә шулай. Ә болай үзе күп сөйләшми. Ярамыйдыр, күрәсең. Икенче тапкыр киткәндә аны башта Түбән Новгородка җибәрделәр, анда озак тотмыйча, Украинага озаттылар. Кичә кич кенә сөйләшкән идек әле. Тик элемтә начаррак булды. Тавышын ишетү, исән-сау икәнлеген белү барыбер рәхәт инде. Сугышка керсә, айлар буе берничә хәбәр булмаган чаклар да булды бит.

Безгә шулай көтәргә язгандыр инде. Әнием башта абыем Маратны көтте. Мин – ирем Наилне, хәзер бергәләп улыбыз Раилне көтәбез. Авыр булса да, мин ирләрен, улларын яшергән, башка илләргә күченеп киткән кешеләрне аңлап бетермим. Бу гамәлне мәгънәсез куркаклык һәм көчсезлек дип саныйм. Дөньяда тизрәк тынычлык урнашсын иде. Бөтен теләгем шул.

Бу теләккә без дә кушылабыз. Көткән кешеләр исән-сау булып, мин кайттым дип, тизрәк туган йортның капкасын шакысын иде.

Раил ГАБДРАХМАНОВ сөйләгәннәрдән:
Безгә Луганск янындагы бер шәһәрдә күпер төзелешен саклау бурычы куелды. Берничә көн дәвамында авыр хәрби техника үтәргә тиешле әлеге җаваплы участокны сакладык. Төзелеш тәмамлангач, мин беренчеләрдән булып елганы кичтем. Арсеналда ике танк бар иде. Дошман тылына үтеп, сугышчан позициягә бастык. Алга куелган беренче бурычыбызны үтәдек. Ләкин икенче көнне төнлә күперне шартлаттылар, ягъни без үзебезнекеләрдән аерылып калдык. Каршы як туктаусыз һөҗүм итте. Бик авыр бәрелеш булды. Коткыга бирелмичә, соңгы снарядка кадәр каршы тордык. Чөнки башка чара да, ярдәм көтәр урын да юк: я әсирлеккә төшәсең, я... Үз бурычыбызны лаеклы үтәдек. Каршы як танкларын тар-мар иткәч, командир белән элемтәгә чыктым. «Сез – герой, зур батырлык эшләдегез», – диде ул миңа. Әмма мин моны батырлык дип санамыйм. Бу – минем эшем.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

88 ЯШЬЛЕК НӘЗИРӘ ШӘРӘФЕТДИНОВА:

«ХАҖГА БАРАСЫМ КИЛӘ»

Чүпрәле районының Иске Кәкерле авылында яшәүче Нәзирә Шәрәфетдиновага үз яшен биреп тә булмый әле. Гәүдәсе җиңел, бер зарланмый, гел хәрәкәттә ул. Җәйгә чыкса, бакча тутырып, яшелчә үстерә, кышларын кәҗәләре белән юана. Язмыш күпме генә сынаса да, ул аңа рәхмәт укый. Бүгенге тормышка сөенеп яшим, ди.

– Бик рәхәттә яшибез бит, кызым. Өстәл тулы ризык. Кибетләрдә нәрсә телисең, шуны саталар. Кияргә кием дә күп. Без бит – бик авырлык белән үскән буын, шуңа хәзерге көннәрне оҗмахка тиңлибез. Бөтен нәрсә чагыштыруда беленә, – дип сүзен башлады ул. – Мин 11 яшемдә ат җигә идем инде. Хәзерге балалар бу яшьтә еламыйча ашамый да. Безнең балачак булмаган да икән ул. Бигрәкләр тиз үскәнбез инде без.

Бик кечкенә гәүдәле була ул. Әмма таза гәүдәле, озын буйлы кызлардан калышмыйча эшли. Бервакыт аларны Киров якларына урман кисәргә алып китәләр. Сер бирми Нәзирә апа. Планны арттырып та үти әле. Урман кисү беткәч, колхозга эшкә урнаша. Авыл кызлары белән бергә иген киптерәләр.

– Нинди генә эшкә куйсалар да, җиренә җиткереп үтәдем. Хәзерләүләр конторасының Иске Кәкерле, Татар Текәсе авылларында, халыктан бәрәңге, сөт-май да җыйдым, фермада сыер да саудым, иминият бүлегендә дә эшләдем. Хезмәтемне һәрчак югары бәяләделәр. Үз гомеремдә дәүләттән бүләккә ике тапкыр «Жигули» алган кеше мин. Өченчесендә гаилә белән бергә Сочига ял йортына җибәрделәр, – дип искә ала Нәзирә апа.

Ире Әнвәршаның да язмышы гыйбрәтле.

– Ирем карында чакта, аның әнисе белән әтисе аерылыша. Менә шуннан башлана аның бәхетсезлеге. Әнвәршага алты ай тулгач, әнисе аны әтисе ягына китереп бирә. Әнвәрша әбисе тәрбиясендә үсә. 6 аенда – әнисеннән, 6 яшендә – әтисеннән, 14 яшендә әбисеннән кала. Ятимлектә үскән, бер кешесе булмаган егеткә кияүгә чыктым мин. Ирем бик акыллы булды. Аның белән яшәгән көннәремне әле дә сагынып искә алам. Бәхеттә яшәтте ул мине. Бер начар сүз дә әйтмәс иде. Гомере генә кыска булды. Сөт ташый торган машина йөртә иде. Бер киткәнендә кире кайтмады. Фаҗигале төстә үлеп китте. Ансыз яшәгәнемә 39 ел инде, – ди Нәзирә апа.

Аларның дүрт малайлары туа. Нәзирә апа барысын да өйдә генә таба. Хастаханәләргә барып йөрми. Шөкер, сабыйлары сау-сәламәт үсә. Тик ике улы, буй җитеп, гаилә коргач, хатыннарын, сабыйларын ятим итеп үлеп китә.

– Азат исемле улым моннан 26 ел элек үлеп китте. Ул чакта кечкенә кызына 2 генә яшь иде әле. Хәзер инде шул оныкның да ике баласы үсеп килә, – дип сөйли Нәзирә апа. – Ул чакта авырлыкларны күтәрергә уллары ярдәм итте. Аларның кайгыртулары, җылы сүзләре йөрәгемне дәвалады. Бала хәсрәтеннән дә авыр әйбер юк икән ул. Улым өчен бик өзгәләнеп яшәдем. Әле бит әтиләрен югалту ярасы да төзәлмәгән иде. Сабыр итәргә өйрәндем. Үземнең исән-сау булганыма, калган балаларыма сөенеп яшәдем. Ирем белән улыма дога кыла алуым да бәхет иде ул чакта.

Тик кайгы җиле алар капкасын тагын шакый. Моннан 11 ел элек Тәүфыйк исемле улы вафат була. Ана йөрәген тагын хәсрәт баса. Әле ярый улының балалары буй җитеп, үз тормышларын корган була. Әбиләре шуларны уйлап юана. Тик кайгы ялгыз йөрми. Улын җирләп ике ай узгач, Тәлгать исемле малаеның хатыны үлеп китә.

– Ул улым да ялгыз яши. 62 яшен тутырды инде. Шулай бергәләшеп гомер кичерәбез. Олы улым Ирек гаиләсе дә ташламый. Барлык балаларым хәлемне белеп тора. Миңа әллә ни күп тә кирәкми. Исән-сау булсалар, шул җитә, – ди Нәзирә апа.

Кечкенә генә гәүдәле ханым авырлыкларны ничек күтәрә алган соң? Диндә булуым ярдәм итте, ди ул.

– Намазга баскач, күңелемә тынычлык таптым. 23 ел буе авылларда мәетләрне юып, кәфенләп йөрим. Аллаһы Тәгалә башкарган эшләремне кабул итсен иде. Шөкер, теләкләрем кабул булып тора. Ике тапкыр хаҗ кылырга барып кайта алдым. Тагын да барасым килә әле. 2019 елның яз башында ук, 2020 ел өчен хаҗга барырга дип, акча күчереп куйган идем. Тик коронавирус аркасында бара алмадык. Акчамны кире кайтардылар да, хәзер инде яшең зур, диләр. Минем кебекләрне алып бармыйлар икән. Ә мин анда үлеп калырга да риза. Киткәндә үк, берәр хәл булса, гәүдәмне алып кайтып йөрмәгез, дип язып калдырам. Тагын бер барып, изге җирләрне күреп кайтып булса иде, – ди Нәзирә апа. – Тормышым җиңел булмаса да, мин язмышыма бик рәхмәтлемен. Атлаган саен рәхмәт укыйм. Сынау килмәгән кеше юк инде ул. Көчле булырга, кайгы-хәсрәтләрне җиңә белергә кирәк. Әгәр син бирешмисең икән, авырлык артка чигенә. Бәхетле көннәр килә башлый. Күңелне ничек тә юатырга белмәсәгез, минем кебек эшкә тотыныгыз. Бер минут та тик торганым юк. Бакчада эш җитәрлек. Көннең ничек узганын сизми дә калам. Тормышны яратып яшәргә, борчуларны уздыра белергә кирәк.

Без кешедән ким түгел!

Казанда яшәүче 24 яшьлек Зәринә Закированың тумыштан аяклары йөрми. Гомере буе арбада утырса да, ул күңелен төшерми. Язмышына риза булып, үзен ничек бар, шулай кабул итеп, башкаларга үрнәк булырга тырыша.

Зәринә – күп кенә бәйгеләрдә җиңү яулаган кыз. «Татарстан энҗесе» бәйгесендә дә матур итеп чыгыш ясаган иде. Инде менә күптән түгел «Невская краса – 2022» бәйгесендә катнашып, җиңеп кайткан. Сау-сәламәт кешеләр иренеп утырганда, арбада килеш Мәскәүгә бару да куркытмаган аны. Зәринә әле дөнья буйлап сәяхәт итәргә дә җыенып тора.

– Башта без гаиләбез белән Киров өлкәсендә яшәдек. Әтием белән әнием Казанга күчеп килергә уйлады. Миңа да зур шәһәрдә ошады. Мин монда бик күп дуслар таптым, – дип сөйли Зәринә.

Алар гаиләдә – ике бала. Абыйсы өйләнгән, хатыны белән өч бала үстерәләр икән.

– Әнием кыз бала буласын белгәч, мине шулкадәр яратып көткән. Анализлары да яхшы булган. УЗИ да кимчелекләремне күрмәгән. Тугач кына табиблар йөри алмаячагымны, башка балалар кебек булмаячагымны әйткән. Ул чакта әнигә дә, әтигә дә кыен булгандыр инде. Гомер буе авыру бала тәрбияләү җиңел түгел бит. Минем дә төрле чакларым булгандыр. Әмма әти белән әнидән бары тик ярату гына тоеп яшим. Мин аларга бик рәхмәтле. Башкалар авыру баланы ташлар да иде. Ә алар минем өчен нишләргә дә белмиләр, – дип сөйли Зәринә.

Өйдә генә укыса да, Зәринә гел белем алырга омтыла. Көллият тәмамлаган. Һөнәре буенча Пенсия фонды белгече булып эшли ала икән. Әмма әлегә ул бу юнәлешне сайламаган. Башка шөгыльгә тотынган. Кызга бик тә кешеләрне матурлау ошый икән. Киләчәктә макияж һәм маникюр белгечлегенә укып, үз эшен башлыйсы килә.

Зәринә авыру булып тугач, әнисе эшен ташлый. Аның тормышы гел кызы тирәсендә генә әйләнә. Арбада йөргәч, әнисенең ярдәме бик кирәк аңа.

– Минем хыялларым бик күп. Сәяхәт итәсем, матур җирләрне күрәсем килә. Аннары башкалар кебек кияүгә чыгарга, сабыйлар сөяргә хыялланам. Аралаша торган дус егетләрем дә бар. Күбрәк интернетта танышам. Мин аларны алдап йөрмим. Беренче язышканда ук үземнең физик мөмкинлегем чикләнгәнен, арбада гына йөрүемне әйтәм. Кайберәүләр куркып кала, кемнәрдер тиз генә юкка чыга. Аралашуны дәвам иткәннәре дә бар. Тик әле мин үз кешемне очратмадым, – ди Зәринә. – Элек мин аралашырга ояла идем. Кеше арасына чыгарга да читенсендем. Әмма республикада минем кебекләргә карата җылы мөнәсәбәт булу яшәргә көч бирә. Син ялгыз түгеллегеңне аңлыйсың. Төрле бәйгеләрдә катнашу ул сиңа талантыңны күрсәтергә генә түгел, дуслар табарга да ярдәм итә. Ә бергә булганда бик рәхәт, бар борчулар онытыла. Йөри алмаган кызларга бер генә теләк: хәзер аралашу өчен мөмкинлекләр күп. Оялмаска, үзеңне ничек бар, шулай яратырга, кабул итәргә кирәк. Без бит беребез дә авыруны сорап алмадык. Җиргә килгәнбез икән, димәк, юкка гына түгел. Матур эшләр белән бу дөньяны тагын да яктыртсак иде.

Игълан тактасы

КЕМГӘ КИРӘК?

12–14 яшьлек кыз бала өчен җәйге киемнәр бар. Кирәк кешеләр редакциягә мөрәҗәгать итсен иде.

Лилия ХАҖИЕВА.
Казан

***

Яхшы хәлдәге, берничә тапкыр гына киелгән 44–46 үлчәмдәге тун, 36–37 үлчәмдәге язгы-көзге аяк киеме бирәм. Күлмәк-чалбарларым да бар.

Энҗе ХӘКИМОВА.
Казан

***

Кемдә бар?
10–12 яшьлек кыз балага яраклы киемнәр кирәк иде.

Луиза ШАКИРОВА.
Лаеш районы

***

12–14 яшьлек малай өчен киемнәр кирәк иде.

МИНЗИЛӘ.
Яшел Үзән

Ярдәм итәргә теләүчеләр булса, 222-09-67 телефон номерына шалтыратсын иде.

ГӨЛДАНИЯ ХӘЙРУЛЛИНА:

«ТАНЫЛУ УЛ ЛОТЕРЕЯ КЕБЕК»

Узган гасырның туксанынчы елларында аның кассетасы сатылмаган, җырлары яңгырамаган берәр урын калганмы икән? Юктыр. «Сафия такмаклары», «Җиләкле җәй», «Сарман» җырлары белән халык күңелен яулады Татарстанның атказанган артисты Гөлдания ХӘЙРУЛЛИНА. Ул ни хәл-әхвәлләрдә яши, татар эстрадасы турында нинди фикердә? Без әнә шул хакта сөйләштек.

:: Җыр ул – ...

– Язмыштыр дип уйлыйм. Тормышта башка сукмакларны сайлап карасам да, язмыш барыбер җыр дөньясына китереп чыгарды. Мин – тимерче кызы. Фамилиям дә Биктимерова иде бит. Кечкенәдән тимер-томыр арасында үскәнгә, мәктәпне тәмамлагач, Казан мотор төзү заводына барып кердем. Станок янында эшләгәндә гел җырлый идем. Шуннан янымa ике егет килде дә, җырлыйсыңмы әллә, дип сорады. Үзем өчен җырлыйм инде, дим, сер бирмәскә тырышып. Безнең гаиләдә җырлау гадәти бер нәрсә иде бит ул. Әни бик матур итеп җырлый иде. Аны хәзер дә, шулкадәр килешле киенә, чибәр, моңлы тавышлы иде, дип искә алалар. Әти тальянда уйный, без – балаларында барыбызда да җырлау сәләте бар. Ә теге егетләрнең вокаль-инструменталь ансамбльләре бар икән, шунда чакыралар. Минем ике туган апам Гүзәл гитара белән җырлый иде, мәктәптә вокаль-инструменталь ансамбльләре дә булган. Озын сүзнең кыскасы, ул җырлаган җырларны мин дә ятлап бетергән идем инде. Менә шул җырларның кирәге чыкты.

:: Ә Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленә ничек килеп эләктегез?

– Аңа кадәр шактый юл үтелде әле. Заводта эшләгәндә, үзе дә шәп җырлый торган бер апа, синең урыныңмонда түгел, дип гел әйтә килде. Безнең белән Лилия Вәлиева да эшли иде. Ул шигырьләр яза, аның текстларына җырлар да язылды. Менә шул кыз мине Ленин исемендәге мәдәният сараена алып килде. Башта хорда җырладым, аннары аерым чыгыш ясый башладым. Баянчыбыз Рәшит Сабировны армиягә алгач, хорга Рөстәм (Рөстәм Хәйруллин, композитор, ире. – **Ред.**) килде, без шунда таныштык. Шушы мәдәният сараенда чыгыш ясап йөргәндә, җыр һәм бию ансамбленә барып карарга тәкъдим иттеләр. Икеләнеп кенә барсам да, ансамбль җитәкчесе Лима Кустабаева, хормейстер Венера Гәрәева мине ансамбльгә кабул итте. Заводта эшләгәндә иртәнге сәгать биштә уяна идем. Һәм һәр иртәдә, и, Аллаһы Тәгалә, миңа сәгать унга гына йөри торган эш бирсәң иде, дип теләдем. Кабул булды бит теләгем! Ансамбльгә эшкә сәгать унга йөри башладым. Өч көн эшләгәч, җырчы Нәфисә Васыйлова бригадасы белән гастрольгә чыгарып җибәрделәр. Анда аппаратура да юк, баянга кушылып җырлыйбыз. Кая гына барсак та, зал шыгрым тулы, халык һәр чыгышны алкышлый. Трактор арбаларында йөрсәк тә, тансык көннәр булып хәтердә калды әлеге сәфәрләр. Җыр дигәннән, бер хәзрәтнең янымa килеп, җырлавыңны ташла, җырларга ярамый дип, үгет-нәсихәт иткәне дә бар. Миңа калса, Аллаһы Тәгалә үзе мине шушы юлга чыгарды. Шулай булгач, ничек җырламыйсың ди инде?! Һәм җыр ул минем язмыш дими, ни дисең?

:: Иң популяр чакта үзегез үк атларны тыя төшеп, күләгәдәрәк калырга теләдегез шикелле. Концертларыгыз булса да, телевидениедә күренми башладыгыз. Моның сәбәбе нидә иде соң?

– Сәхнә юлым озын, шөкер. Читтән караганда гына танылу тиз килгән кебек ул. Мин исә башта үзешчән сәнгатьтә чарландым, аннары Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамблендә түл җыйдым. Моңа Түбән Кама музыка училищесында укуымны да өстәргә кирәктер. Беләсеңме, уку авыр булмады, ул шәһәрдә яшәү авыр булды. Нишләптер Чаллы белән Түбән Кама шәһәрләре күңелемә ятмый иде, тик икесендә дә яшәргә туры килде. Гомер-гомергә Казанны яраттым. Телевидениедән читләшүнең сәбәбе сәламәтлеккә бәйле. Битем бозылды, аны бик озак дәваларга туры килде. Андый йөз белән чыгып, кешедән кызгану сүзләрен ишетәсем килмәде. Аңа карап кына иҗат тукталмады, билгеле. Концертлар уза торды, аларны архивка төшерү генә булмады. Ә аннан инде телевидениедә җитәкчелек алмашынды, мине чакырмый да башладылар. Рөстәм вафатыннан соң бер-ике еллап вакыт узгач, җырлар яздыра алдым. Шул язмаларны алып, концертымны төшереп булмасмы икән дигән үтенеч белән Миләүшә Айтуганова янына кердем. Берсүзсез риза булды. Нәтиҗәдә кичке уннан иртәнге өчкә кадәр камералар алдында концерт куярга туры килде. Һәрбер җырга кием алмаштырасы да килә бит әле. Бу кадәр җентекләп беркемнең дә төшкәне юк иде әле, диделәр.

> Гомер буе үземә тәнкыйть күзлегеннән карадым. Җырларны кечкенә бер спектакльгә әйләндерергә тырыша идем. Концертта чыгышлар цирк номерлары белән дә баетылды, кием алмаштыруны әйткән дә юк. Ә инде җырлаганда ялгыш бер хата китә икән, аны телевидениегә дә, радиога да чыгармаска тырыша идем.

:: Сез – заманнан калышмаган, яшьләр теле белән әйтсәк, «продвинутый» җырчыларның берсе. Кызыгыз Лилия белән кызыклы видеолар төшерәсез, төрле тәҗрибәләрдән дә курыкмыйсыз.

– Кызым белән кыска видеолар төшерү минем өчен бөтенләй ят нәрсә иде. Пандемия чорында башланып китте ул. Кешеләрне хәвеф, төшенкелектән арындырасы килү дә үз эшен эшләгәндер, бәлки. Концертлар да туктап торган вакыт иде. Башта Лилия бер видео күрсәтте дә, әйдә без дә шушылай төшереп карыйк әле, диде. Әлбәттә, ризалашмадым, кит аннан, мин әйтәм, халык, Гөлдания акылдан шашкан дияр, дим. Ахыр чиктә барыбер күндем. Видеоны интернетка чыгаргач, халык ничек кабул иткәнен күрдек. Дөрес, каршы язучылар да булды, елмаеп, кәефне күтәрдегез, диючеләр барыбер күбрәк булды. Шуннан китте инде. Съемкалар вакытында үзебезнең дә кәеф күтәрелде, мөгаен, караучыларга да шул тәэсир иткәндер. Биюләр дә төшергән булды. Караганда кызык инде ул, әмма шушы кыска гына видео да бик озак төшерелә икән. Лилиянең ачуланган вакытлары да булды хәтта. Чөнки камерага мавыгып уйнап китәргә дә ярамый, кызык та чыгарырга кирәк, шул ук вакытта ихласлык та югалмасын. Бик читен икән ул. Эшләп карамыйча гына белеп булмый икән аны. Заман дигәннән. Шушы вакытта яшисең икән, вакыт куйган таләпләрне кабул итми, заман белән бергә атламый булмый инде ул. Башка юл юк. Шулай да, үземне яшьләрдән бик күпкә артта дип саныйм. Әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе. Кеше гомер буе өйрәнергә, укырга тиеш, миңа калса. Шул чакта гына тегенди-мондый уйларга вакыт калмый.

:: Иregez Рөстәм абый иҗаты онытылмыймы? Аның җырларын башкаралармы әле?

– Рөстәм бакыйлыкка күчкәндә Лилия институтта укый иде. Әтисеннән кечкенә килеш калмаса да, аңа да, миңа да бик авыр булды. Юатучылар, бер ярты елдан җиңеләя, вакыт дәвалый, дип әйтәләр иде. Аны җиңеләя дип әйтеп булмый. Ул яра булып кала бирә. Шуның белән бергә яшәргә өйрәнәсең. Тормыш дәвам итә дип, үзеңне кулга аласың. Шул гына.

Рөстәмнең җырларын бик күпләр башкара. Әйтик, Айдар Галимов, Резедә Шәрәфиева, Равил Галиев, Ришат Фазлыйәхмәтов, Гүзәл Уразова, саный китсәң, шактый. Еш кына җырның авторларын бик әйтеп тормыйлар, халык ул җырның авторларын белеп тә бетерми. Шуңа Рөстәмнең берничә җырын искәртеп китик әле. Мәсәлән, Ришат Фазлыйәхмәтов Рөстәмнең «Яшәтәсе килә әнкәйләрне» (Нурислам Гафиятов сүзләре) җыры белән «Татар җыры»нда лауреат булды. Хәния Фәрхи башкарган «Күп сорамыйм синнән, язмышкаем», Салават башкарган «Җиләкле җәй» җырларының да көй авторы – Рөстәм Хәйруллин. «Җиләкле җәй»не башта мин яздырган идем, Салават сорап алды һәм бу җыр бик популярга әйләнде. Хәзер кызым Лилия башкара. Мин дә аннан аранжировкасын сорап алып җырлыйм.

:: Тәнкыйтькә ничек карыйсыз?

– Мин болай дим: күп эшләгән кешенең эше күренә. Эш күренгәч, аңа уңай караш та, тискәресе дә була. Популярлык арткан саен, тәнкыйть тә арта. Бу – табигый. Мин белгечләрнең тәнкыйтенә бик уңай карыйм. Ә инде теләсә кемнең теләсә нинди фикер язуына елмаеп карарга өйрәндем. Мөнәсәбәт белдермәгәч, күрәсең, кызык булмый башлаганмындыр, миңа бик бәйләнмәделәр. Лилия дә тәнкыйтьне тыныч кабул итә.

:: Җырчы Лилия Хәйруллинаны әнисе белән чагыштыралармы?

– Баштарак андый хәлләр булды. Ул чакта Лилия күбрәк халыкчан җырлар башкара иде. Аннан ул стилен үзгәртте, үз юлын тапты, репертуарын булдырды. Репертуарында халык җырлары да бар, билгеле. Һәр җырчы халык җырын башкарырга тиеш, миңа калса. Иң кызыгы: ул да бит башта, җырлый булмыйм, дигән иде. Цирк студиясендә шөгыльләнде, Шәрык биюләрен дә өйрәнде. Гомумән, күпкырлы ул. Ә җырлап китүенә әтисе сәбәпче булды, дисәк тә була. Әтисенең «Бирмә мине беркемгә дә» дигән җыры аны эстрадага алып чыкты. Бөтен җиргә үзе йөрде, кечкенәдән мөстәкыйль, эзләнүчән булды. Безнең белән гастрольләргә йөрде, иртәнге якта кайтып керсәк тә, мәктәбенә йөгерә иде.

:: Татар эстрадасы бүген ни хәлдә?

– Эстрадада бүген нинди генә алым, нинди генә тавыш юк. Кибеткә кергәч, товар күплегеннән башың әйләнеп, сайлый алмыйча торасың бит әле, эстрада да бүген тамашачының башын шулай әйләндерә. Рэп дисәң, рэбы бар, халыкчан тавыш кирәк дисәң, анысы бар – иренмичә сайла да тыңла гына. Мин эзләнгән кешеләрне яратам. Шуңа яшьләрне күзәтәм, алардан нәрсәдер өйрәнергә тырышам. Җырчыга бүген җиңел түгел. Чөнки бөтен җырчы да популяр булып бетә алмый. Алар һәр заманда да исәпле генә булган. Монда акчасы булганнар популярлык казана дигән фикер дә бик дөрес түгел. Акча түгеп, халык теленә керсәң дә, андый популярлыкның гомере кыска. Шул ук вакытта бик шәп тавышлы җырчылар да популярлык казана алмаска мөмкин. Ул лотерея билеты кебек. Я әләгә сиңа бәхетле билет, я юк.

:: Популярлык кими башлагач, социаль челтәрләрдә гаугa чыгару, шәхси тормышны чагылдыруга ничек карыйсыз?

– Элек тә бар иде ул шул рәвешле үзеңне рекламалау, хәзер инде бигрәк тә күп кулланалар бу алымны. Белмим, минем өчен иҗат – бер, гаилә – икенче нәрсә. Бөтен нәрсәне халыкка чыгаруны өнәп бетермим.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВА

УМАРТА

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

< Дәвамы. Башы 14, 21 октябрь саннарында

Кичкә хәтле карчык-корчыклар авыз эченнән туктаусыз укыштырып, ирләр белән хатыннар юк мәшәкатьне бар итеп көнне сузып йөрделәр дә урамда бер-бер хәрәкәт күренмиме дип, койма аша муеннарын сузып караштыргалый башлаганнар иде, шул вакыт «яңа гына табадан төшкән мулла»ның ишеге дөбер-шатыр килеп, киерелеп ачылып китте. Аннан шактый кызмача көйгә хромка гармунын тотып, Габит мулла чыгып басты. Өстендәге күн кәжәне белән аягындагы кирза итеге шыгырдап тора, чегәннеке кебек кара бөдрә чәчләре башындагы күн кепкасы астыннан салынып төшкән. Баскычка чыгып та басты, гармунының бакасына басып акыртты да: «Кыммарикаааа!» – дип сузып җибәрде. Ишегалдында чирәмдә утлап йөргән кәҗә бәтиләре төрле якка чәчелде, тәкәсе, акаеп, хуҗасына карап тора башлады. Гадәттәгечә Зиннурларның капка төбенә җыелышкан ирләр телсез калды. Мондый ук иде. Фатыйма табын әзерләү белән мәшгуль, остабикәне Мостафа каршы алды. Анысы озакка сузмады, исәнлек-саулык алышкач, тизрәк бишек янына килеп укый да башлады. Ярый әле тиешле догаларны укып бетерә алды, колагына исемен пышылдыйм дип, бәбинең йөзен ачкан иде, телсез калды. Валлаһи, бер кәлимә сүз әйтә алмас булды. «Нәрсә булды?» – дип сорамакчы булып авызын ача, ләкин бер сүз чыкмый. Нәүмизләнеп йорт хуҗаларына карый, тегеләре дә берни аңларлык түгел. Ярый әле Фатыйма абайлап алды, тизрәк чүмеч белән су китереп бирде, Ләйлинур әбине диванга утыртты. Су эчкәнгә карап кына теле кайтмады, әби чын-чынлап курыкты: бөтенләйгә шулай булып калса? Шуңа да Ләйлинур әби Мостафа белән Фатыйманың ай-ваена карамыйча, җәһәт кенә итәк-җиңен җыйды да чыгып та китте. Өенә кайтып, күпмедер вакыт узгач кына «Йа Алла!» дип әйтә алды. Тиз генә чәй куеп, йөзем җимешләре кабып чәй эчкәч кенә, хәл керде үзенә. Бала исемен тамашага әзер түгел иде әле алар. Телсез каласы көннәре моның белән генә бетмәгән булып чыкты.

Хикмәт шунда: Мостафаның тәпчек кызына Нәфисә дип исем сайладылар. Бәби туып, биләүгә төрү белән өйдәгеләр аны күреп телсез калды: анда тиңе булмаган гүзәл бер бала ята иде. Нәфисәнең бер атнасы тулганчы, Ләйлинур әбине чакырып, исем куштырмакчы булдылар. Мул итеп табын әзерләделәр, Мостафа белән хатыны Фатыйманың ике улдан соң, бик теләп алган кызлары иде ул. Ак биләүгә дә биләделәр, бәхет тә теладеләр. Фатыйма да, Мостафа да биләүдәге кызга карап, нишләргә белмәде. Моның кадәр дә камил, гүзәл баланы күргәннәре юк иде әле. Ике абыйсы Илнур белән Илсур Нәфисә кызчыкның бишеге янына сакка басырып куйган солдатларга әйләнде, сеңелләрен бер мизгелгә дә калдырмас булдылар. Янына берәүне дә китермиләр, бәби ашы кертә кергән күршеләрен дә бишеккә якын җибәрмиләр. Азан әйтеп, исем кушарга кирәк, дип үгетләгәч кенә, Ләйлинур остабикәне чакырырга ризалык бирделәр. Ул арада Мостафаның бик тә гүзәл кызы тууы турында хәбәр авылга таралып өлгергән иде инде, бәби күрергә теләүчеләрдән чират җыелды.

Ләйлинур әби, исем кушарга хәзер безнең авылда мулла бар, Габитка әйтегез, дип караса да, берсе тугыз, берсе унбер генә яшьлек Илнур белән Илсур ризалык бирмәде. Ни кырыс Мостафа да үгеткә кертә алмады үзләрен. «Муллагыз да, абыстаегыз да кирәкми, теләсә кемне чакыры булсагыз, Нәфисәне алып качабыз», – дип куркыттылар. Алар инде болай да моңа кадәр бик шук, бик чая балалар булып, әниләре Фатыйма катырак әрләгән саен, чыгып качалар да төн авышкач кына «Сак-Сок» көен көйләп кайтып керәләр иде. Ышанырсың икән, баланы алып чыгып качарлар. Фатыйма үзе әкиятләр белән генә үстерде шул аларны. Мостафа атналар буе чит авылларда йорт салып йөргәндә, төннәр озын, малайлар төн кошлары кебек йокламыйча аптыраталар иде.

Ләйлинур остабикә ак яулыгын җилкәсенә салып бәйләп, бер кулына дисбесен, икенчесенә Һәфтиякләрен тотып кергәндә, Нәфисә кызчык бишегендә ята кабул итмәде, шуңа күрә дә фәрештәләр телемне кисте, дип уйлады ул бераз аңына килгәч. Тынгысызланып, янә Фатыймага кереп китте. Шик-шөбһәләрен сөйләп бирде-бирүен, тегеләр генә артык илтифат итмәде. «Ләйлинур түткәй, бер дә аптырама, кем белән булмый андый хәл! Нәфисәбез кабул иткәндер исемен, син чыгып китүгә изрәп йоклады», – дип тынычландырды алар остабикәне.

Ләкин Ләйлинур остабикә белән булган хәл башкалар белән дә кабатлана башлагач, алар пошаманга төште. Кем генә кереп, Нәфисәгә күз салмасын, барысы да телләрен йоткандай, сүзсез калалар, сөйләшә алмыйча нәүмиз булалар иде. Сүзсез калу гына бер хәл әле, аларны эчтән ниндидер бер билгесез хис билэп ала, алар бу хисне тел белән аңлатып бирә алмый, шуңа да аннан куркалар иде. Бу хәбәр Каракүлдә яшен тизлеге белән таралды.

Чыннан да шулаймы-түгелме икәнен сынар өчен халык Мостафаларга агылды. Бу хәлгә Илнур белән Илсурның түземе тиз төкәнде. Алар кечкенә сеңелләрен болай да кешегә күрсәтергә атлыгып тормый иде, хәзер инде килгән берсен капкадан ук куып җибәрер булдылар. Шулай итеп, беркая чыкмыйча сеңелләрен саклады лар. Мостафа белән Фатыйма нишләргә белмичә аптырап калды. Иң элек аларны кызларының бүгенгесе түгел, әкиләчәге борчый иде. Гомергә шушындый хикмәте белән яшәргә язганмы Нәфисәгә? Ничек үстерергә дә ничек итеп тәрбияләп бетерергә? «Син гаепле», – диде беркөнне Мостафа Фатыймага. «Нишләп мин? Син!» – дип каршы төште тегесе. Шуннан артык сүз булмады. Һәркайсы үз казанында кайната иде уен. Гаепләр өчен дәлил кирәк иде – тапмадылар. Озак уйланды Мостафа. Фатыйма да озак баш ватты. Ләкин сабый янына килү белән бөтен борчулары, шик-шөбһәләре юкка чыга иде.

Ул арада Каракүл халкы бу мәсьәләдә икегә бүленде. Берәүләр бишектәге сабый баланың кешеләрне телсез итә алу сәләтен шайтан коткысы дип бәяләде. Шайтан матурлык белән алдый, дигән дәлил китерделәр. Яхшыга түгел бу, чарасын күрергә кирәк, дип пышылдаштылар. Икенчеләре, киресенчә, аны Аллаһ могҗизасы итеп кабул итте. Рәхмәте белән туган бала булсын, сөенеч китерер әле, дип көтте. Аллага да, муллага да ышанмый торган Хәләф халыкның үзеннән көлде. «Бөтен бәла шул ышанулардан», – дип гадәттәгечә кул селтәде ул. Кемне-кемне, кайчан карама салмыш, тәмәке исенә баткан Хәләфкә Нәфисәне күрсәтмәячәк иде инде Илнур белән Илсур. Тегесе дә, күрәм, дип ашкынып тормады. «Шайтан да, фәрештә дә түгел, гап-гади гипнотизёр, экстрасенс. Тумыштан шарлатан», – дип нәтиҗә ясады ул. Ә Нәфисә тиңе булмаган бер матур бала булып үсә торды. Әтисе белән әнисе дә, ике абыйсы да телдән язмый иде аның янында. Шуңа да нарасый үзенең бүтән төрле икәнен сизми иде әле. Сабый чакта аңа әтисе оста куллары белән шыгырдап торган бүрәнәдән салган алты почмаклы өй дә, юкә агачлары белән әйләндереп алган бакча да җитә иде.

Көннәрдән бер көнне аны бакча гына канәгатьләндерми, ул өйдәгеләрдән капканың теге ягына алып чыгуларын таләп итә башлады. Бүтәннәрне телсез итә торган булса да, үзенең теле иртә ачылды Нәфисәнең. Бертуктаусыз сөйләшеп, сорау биреп йөдәтеп бетерә. Өйдә ул гапгади бала кебек булгач, Мостафалар тынычланып калган иде. Аларга кеше-фәлән кереп-чыгып йөрмәвенә дә күнектеләр, үзләре дә тышкы дөнья белән алыш-биреште шактый киметте.

Көннәрдән бер көнне Нәфисә койма арасыннан урамга чыгып китте. Илнур белән Илсур мәктәпкә киткән, Мостафа – мал арасында, Фатыйма ишегалдындагы вак-төяк эшне эшләп йөри иде. Әнисе янында такылдап йөргән кыз берара тавыклар куып уйнады да чуар тавык артыннан йөгереп, карлыган куаклары арасына ук кереп китте. Нәфисә урамда малайлар тавышы ишетеп, коймага терәлде. Ә анда күптән тотылган койма тактасы черегән дә, кадагында чак эләгеп тора иде, бәләкәй бала авырлыгына да киртәсеннән аерылып китте. Кызчык үзе сыярлык тишек күрүгә, шунда ук аны зур дөньяга ишек итеп, теге якка атлап чыкты. Ниндидер бер эчке дәрт, кызыксыну аңа йөгерергә куша иде. Курку турында уйламады да, борылып та карамыйча чапты гына. Кечкенә кызчыкның нәни аяклары җиргә тигәндерме, юктырмы, ул дөньяның киңлегеннән кинәнеп, аны иңләрдәй булып көлә-көлә алга йөгерде. Аның каравы мәктәптән кайтып килүче малайлар олылар арасында пышылдауга күчеп кенә сөйләнә торган «ахырзаман баласы»н урамда берүзен күреп, шаккатып карап калдылар. Малайлар арасында Камил дә бар иде. Ул уйлап-нитеп тормады, Нәфисә артыннан чапты. Кечкенә кызны куып тоту озак түгел, ике атлап бер сикерүгә янына килеп тә басты. Бәләкәй кыз Камилне күреп туктап калды, аның да чит кешене болай якыннан беренче тапкыр очратуы бит. Малайның да бик күпләр кебек кызны беренче күрүе. Билгеле инде, ул да телсез калды. Нәфисә, чыннан да, сүз белән генә әйтеп бетерә алмаслык матур кыз иде. Сокланугa тагын әллә нинди таныш түгел бер уңайсыз хис килеп кушылды. Малай эчтән куырылып килде, алай булса да үзе кызчыктан күзен ала алмады. Нәфисә Камилне баштанаяк күзәтеп чыкты да кулыннан җитәкләп алды, алга әйдәкләп тарта ук башлады. «Әйдә тизрәк, әйдә», – дип ашыктыра иде ул. Малайның каршы дәшә алмыйча, сихерләнгән кеше кебек иярүдән башка чарасы калмады. Урамның теге башында мәктәп икәнен, озакламый аннан йә Илнур, йә Илсур чыгачагын бик яхшы белсә дә, Камил берни эшли алмый иде. Мәктәпкә килеп кергәндә, соңгы дәрестән чыгарга дип кыңгырау шалтыраган гына булган, күрәсең, коридор тулы кеше иде.

Дәвамы бар >

Шигърият

Марат КӘБИРОВ

СОҢГЫ ОЗАТУ

Мин юлларга китәм инде...
Юлларга китәм инде.
Син беләсең кайтмасымны,
Мин беләм көтәреңне.

Елмаеп, кул болгап калдың,
Кузгалмый озак тордың...
Бу – минем соңгы китүем,
Бу – соңгы озатуың.

Китеп бардым. Көтеп калдың.
Аралар еракланды.
Еламадык. Араларда
Мәхәббәт елап калды.

Мин китәмен, син каласың,
Кемгә калырсың инде?!
Кемгә калсаң да, барыбер
Көлгә калырсың инде.

* * *

Чынбарлык, я әкият дисәң дә –
Янда йөри кара бер шәүлә.
Йөрәгемне йөри яралап –
Төннең күзеннән дә карарак.

Үлем дә юк аңа, үлчәм дә...
Җанда йөри кара бер шәүлә...
Кайлардадыр кулкан вөрмә
Өерелә минем вөмдә...

«Караңгылык түгел ул! – диләр, –
Бу тик бары – кара нур гына...
Син колак сал асыл затларның
Яктылыктан зарлануына».

Мин ышанам. Атлыйм. Абынам.
Нурның якты чагын сагынам.
Сагышлардан язмыш аралый:
«Юк, сагынма, абзый, ярамый...»

Караңгылык буйлап янамын –
Берүзем бер якты ярамын...
Берьялгызым тоеп барамын
Яктылыкның кара газабын.

Тирә-якта кара төн генә,
Көнме инде, төнме – кем белә.
Телем-телем йөрәк телена...
Төшә икән кемнең эзенә?

Караңгы нур баскан дөньядан
Үги бала булып мин барам.
И, ни әйтим инде... Бу илдә
Кем бар инде үги булмаган?..

Кемнәрнедер яшәү үтерә,
Кемнәргәдер үлем юл ача.
Бер яктырыр сыман бу дөнья...
Иртәгәдер... Бүген булмаса...

Ә барыбер дөнья яктырыр...
Тик кемгәдер ул да ят булыр...

КЕШЕ

Чәчәкләр кала үрелеп,
Назлы җил үбеп ала...
Таң кояшы кебек балкып
Язларга кереп бара.

Дөньяга ул хуҗа сыман,
Үз җырын сузып бара.
Мин – язда, дип уйлый-уйлый,
Җәйләрен узып бара.

Җанындагы яз кояшын
Күзләрдән алып бара.
Кояш инде офыкларны
Алтынга манып бара.

Юлларын да, җырларын да
Бураннар күмеп кала...
Бураннарны да күрмичә,
Кышларга кереп бара.

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 **ЯЗЫЛ!**
2023 елның беренче ярты еллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына язып

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘККӘ**
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435
җомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама

Әз-мәз мәзәк

– Сезнең оешмада бераү дә эшкә соңга калмый. Мондый тәртипкә ничек ирештегез?
– Бездә 20 кеше эшли. Ә парковкада урыннар 10 гына.

* * *

– Әни, физрук безне дәрестә мыскыл итә.
– Ничек итеп?
– Футбол кырын биш тапкыр йөгереп узарга куша, ә үзе безнең белән йөгерми.

* * *

Нинди могҗиза ул сода? Аның белән коймак та пешерәләр, унитаз да чистарталар.

* * *

– Балалар, бүгенге дәрестә без «Мин миллионер булсам» дигән сочинение язабыз.
Унбиш минуттан:
– Кәрим, син ник язмый утырасың?
– Секретаршамны көтәм.

* * *

Бүген үз-үземә бикләндем. Карале, шәп икән бит анда!

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Пошалым, Гази, чаршау, Али, Изаура, Мамадыш, Әлфис, алты, мәк, Хәлим, семестр, ки, фа, шәл, аз, иш, Марсилия, сыгылу, Ре, Зәйнәб, ТТ, табышмак.

Вертикаль: чалма, бенефис, Камал, ашы, рәт, Римма, Грейт, Си, еш, Баруди, мәмләкәт, По, елау, ба, ишәк, бәртәс, арфа, Илмир, Рөстәм, КАИ, машина, Ык, Кизяков.

Файдалы киңәшләр

✓ Йомырка тәбәсен кечкенә түгәрәклəр формасында пешерергә була. Моның өчен бөкрә итеп киселгән суган телемнәрен кулланыгыз.

* * *

✓ Суыткычта сыр катмасын дисәгез, аңа атланмай сылап куярга була.

* * *

✓ Табага тоз салып җылытсагыз, ризык ябышмаячак.

* * *

✓ Кайнар чәйне, Салават яратканча, салкын итеп эчәсегез килсә, чынаякка биш-алты кашык тыгып куегыз. Металл кайнарлыкны үзенә алыр.

* * *

✓ Янчык эченнән начар исне бетерәсегез килсә, аның эченә бер-ике пакетлы чәй ташлау киңәш ителә.

* * *

✓ Буяу банкасына резинка кидереп куйсагыз, пумаладан артык буяуны сыдырып алырга җайлы булыр.

* * *

✓ Буяу эшенә тотынганчы, кулларыгызга бераз крем сөртегез, соңыннан бармакларга эләккән буяуны сөртеп алырга җиңелрәк.

* * *

✓ Савап эшлисегез килсә, бу киңәшләрне башкаларга да сөйләгез.

Казандагы театр
Кытай илбашы
Рөстәм Закировның чаналы авылы
Мулла башында
Рейхстаг өстенә әләм кадаган ... Заһитов
Язучы Эдгар ...

Боксчы Мөхәммәт ... (1942–2016)
Карават тирәли пәрдә
Парижга аның аша баралар
Хуҗа Насретдин «аты»
Кыллы музыка уен коралы
... Асаев
ОСАГО булмаса, йөрми
... Ибраһимова
Урамы булган Галимҗан ...
Җырчы ... Кыямов
Очкылык тоту елгасы
Язучы концерты

4+2
Елга балыгы
Кызыл чәчәк
«Когда все дома» алып бара
Балавыз сыгу
Шоумен ... Ямалов
КНИТУ-...
Нота
Кисәкчә
Югары даимилекле
Күгәрчен авылы тавары
Уку елының яртысы
Чүт кенә
Тиңдәш
Татар эстрада җырчысы
Футболчы Кайетано ...
«Бәби ...» мәҗлесе
«Урал-...» баскетбол командасы
Кармакка кирәкле сыйфат
Кәеф, көч, дәрт
Гарәп хәрефе

«Бу җырым сиңа бер ...»
«Ауди» машинасы төре
Ил, дәүләт

Беләсең килсә...

1 Аргентина дәүләте нәрсә хөрмәтенә шулай аталган?
а) агач;
б) металл;
в) газ.

2 1858 елда Казанда кем кунак булган?
а) Александр Дюма;
б) Александр Пушкин;
в) Александр Блок.

3 «Дедлайн» сүзе нәрсәне аңлата?
а) куелган максат;
б) соңгы срок;
в) бабай начар.

4 Актриса Наталья Державина 30 елдан артык бу курчак булып сөйләште:
а) Хрюша;
б) Степашка;
в) Каркуша.

Җаваплар: 1. б); 2. а); 3. б); 4. а).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррирнең беренче урынбасары – ХӨСНУЛЛИН Илнар Хәлил улы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15318 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 359

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+